

Фирая Зыятдинова

# УТНЫҢ ЯШИСЕ КИЛӘ

Шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)—5
З 82

**Зыятдинова Фирая**

З 82 Утның яшисе килә: Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 175 бит.

Җыентыкка шагыйрәнең лирик-фәлсәфи һәм балалар өчен язылган шигырьләре тупланды.

ISBN 5-298-04112-4
© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Фирая Зыятдинова, 2005

# КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫЙК!

*(Лирик-фәлсәфи шигырьләр)*



* * *

Җиргә әллә чык тамчысы,
Әллә күз яше тамды...
Сөйләгез барын яшерми –
Кайсыгыз моңлы-зарлы?

Җирнең моңлы балалары,
Яратам барыгызны.
Килегез әле яныма,
Сөйләгез зарыгызны.

Сөйләгез берни яшерми,
Сөйләгез барын-барын...
Юрармын ак юллар сезгә,
Шатлыклар гына бары!

Суга туймас гөлләр сыман
Кыз баланың күңеле.
Таңнар туса, җир йөзендә
Сөю эзләгән көне.

Гөлләргә дәшеп бага ул,
Сандугач баласына.
Эзләгәнен табар сыман
Җыр юлы арасыннан.

Бәхет өчен, сөю өчен
Яратылган кыз бала.
Дөньяга дәшеп бага ул,
Кояшка дәшеп бага.

Эзләсен, әйдә, бәхетен,
Эзләгән генә таба.
Суга туймас гөлләр сыман –
Назга туймас кыз бала.

Төнне тизрәк уздырасы,
Таң аттырасы килә.
Тимәгез сез кыз балага –
Яраттырасы килә.

## КЫЗЛАР САГЫШЫ

Челтерәп чишмә акканда
Моңланмый буламыни?
Тиктән генә керфекләргә
Энҗе яшь кунамыни?

Чишмә агышлары түгел,
Еллар агышы бит ул.
Яшь гомернең әкрен генә
Үтеп барышы бит ул...

Кызлар озак сагышланмый:
Әнә тагын елмая.
Әнә тагын кояш чыга,
Дөнья тагын нурлана.

Кыз баланың йөрәгенә
Ак өметләр юл ала...

## ЯШЬЛЕК

Бер кыз килә көлә-көлә
Чәчәкләр арасыннан;
Күзләреннән чишмә булып
Җылы нур ага сыман.

Болын буйлап бер кыз килә,
Унсигездә ул – көлә...
Мин дә елмаймакчы булам, –
Никтер елыйсы килә...

* * *

Айның әле яңа гына
Туып килгән чагы;
Сине болай яратучы
Булды микән тагы?!

Айның инде алма кебек
Тулып килгән чагы;
Сине болай яратучы
Булыр микән тагы?!

## БУ ӨЧ КӨНЛЕК ДӨНЬЯ...

Без кунакка килгән, имеш, монда:
Юк, эшләргә килгән без Җиргә.
Адәми зат шушы Җир-җиһанда
Кырмыскалар кебек мәш килә.

Көндез – Кояш, төнлә Ай елмая,
Берсе – дәртле, берсе – моң тулы.
Күңелләрне әллә кая илтә
Тезелеп киткән Киек Каз Юлы.

Көннәр, төннәр, еллар үтә тора,
Картаясың, бала, дип тормый.
Син китәсең, Ай, йолдызлар кала –
Барысы да кала, дип тормый.

Ник килгәнмен ашыгыч бу дөньяга?
Өнемме бу минем, төшемме?
Бу өч көнлек дөнья... Бабамнарның
Сүзе дөрес икән – төшендем.

Шул өч көндә син эшләргә тиеш
Иң куәтле аттай җигелеп.
Синнән тора: җиңеп китәсеңме,
Китәсеңме әллә җиңелеп...

## СЫЗЛА, ЙӨРӘК, СЫЗЛА!

«Кеше өчен утлар йотып,
Йөрәгеңне бозма!»
Юк, юк, Йөрәк, бозыл,
Сызла, Йөрәк, сызла!

«Гаделсезлекләрне күреп,
Утлы таштай кызма!»
Син дә тыныч, мин дә тыныч...
Сызла, Йөрәк, сызла!

«Егылган – үзе гаепле...
Сузма кулың, сузма!»
Әгәр үзең егыла калсаң?..
Сызла, Йөрәк, сызла!

## АКЫЛ БЕЛӘН ЙӨРӘК

Моң дәрьясы ярларыннан ашкан –
Ничек чыдый адәм баласы?
Корыч булып корыч эрер монда,
Башны ничек саклап каласы?

Моңсыз яшәү Җирдә күңелсез дә,
Баш та кирәк гомер итәргә.
Акыл белән Йөрәк дус яшәсә,
Матур булыр иде иртәләр.

## БЫЕЛГЫ ЯЗ

Быелгы яз әллә нинди –
Үзе ярсу, үзе тын.
Йөрәкләрне алгысыта
Әллә шатлык, әллә моң.

Тиктомалдан күңел тула –
Елыйсы килә сыман.
Йә тургай булып сайрыйсы,
Җырлыйсы килә сыман.

Көмеш тамчыга әйләнеп
Тамасы килә кебек;
Кар суларына кушылып
Агасы килә кебек.

Күңел язгы күлдәвектәй
Түгелеп китәр төсле.
Шушы язның ярсу моңы
Гомергә җитәр төсле.

## УТНЫҢ ЯШИСЕ КИЛӘ...

Күккә ашар сыман бер талпынды,
Аннан җиргә ятып елады.
Үкседе дә тәмам тынып калды...
Юк, ул әнә тагын тын алды.

Бии-бии күккә үрләде ул,
Төннең кочагына сыймады.
Ут җаны да кеше җаны кебек –
Яшәүләрдән мәңге туймавы...

## БЕЛДЕМ – БЕЛМӘДЕМ

Сөрдем җирнең катламнарын –
Төшендем күк бераз серен.
Сөрдем күңел катламнарын –
Берни белмәвемне белдем.

* * *

Ник болай еш бәргәләнә йөрәк?
Ник сулкылдый инде җаннарым?

Болай нечкә булмас иде күңел,
Сезнең кардәштер мин, талларым...

* * *

Бу дөньяның даны, дәрәҗәсе
Кызыктырмый мине һичничек.
Үз дөньямда яши алсам иде,
Сират күперләрен сау кичеп.

* * *

Каргаларны өнәп бетермиләр –
Илдә халык сандугачка гашыйк.
Каргаларны хәтта сагынып кайттым,
Сандугачлы чит-ят җирдән качып.

## ГАҖӘП!..

Кыш буе яуган карны
Язның бер көне
Бик кызык итте:
Бөртекләрдән өелгән
кар тавы
Су булып акты да китте...

* * *

Кузгатмагыз иске яраларны –
Кузгалырга тора яңалары...

* * *

Үргә мендем, дип куанма:
Үр артында үрләр бар.
Серен алдым, дип юанма:
Сер артында серләр бар.

* * *

Без көн саен шулай юанабыз,
Горур күтәрелгән башыбыз:
– Без моңарчы яши белмәгәнбез,
Иртәгәдән яши башлыйбыз...

## ТИК ЯРАТЫП...

Без һәрвакыт яратырга тиеш,
Яратмау ул – Җирдән юк булу.
Ә ярату – йөрәк тулы әрнү,
Ярату ул тоташ ут булу.

Утлар бит ул җылытып кына калмый,
Яндыра да көлгә калдыра.
Җаннарыңа сөю бик еш кына
Сары сагыш булып сарыла.

Котылу юк Җирдә сагышлардан,
Котылу юк вакыт-еллардан...
Янсак яныйк, көлгә калыйк, әйдә,
Тик яратып китик дөньядан.

* * *

Болын тулы чәчәк. Тургай җыры.
Агыладыр өстән көмеш моң.
Күпме җырласаң да туеп булмый
Матурлыгын шушы тормышның.

Кояш күтәрелә – нинди матур,
Чык җемелди гөлләр күзендә.
Күңелемнең ничек нечкәргәнен
Сизми калам кайчак үзем дә.

Кунак булсаң, тыйнак бул, ди халык,
Күктән иңгән сүз ул – мин беләм.
Сагыш белән түгел, Җир-анабыз
Тулып калсын бездән моң белән.

## БЕРКЕМ БЕЛМИ...

Тормыш – Чәчәк. Матур. Чәнечкеле...
Серләр яшеренгән бу Чәчәккә.
Беркем белми каян килгәнлеген.
Белми. Беркайчан белмәячәк тә...

* * *

Табигатьтә бар нәрсә дә камил,
Җирдә бар да үсеш, хәрәкәттә.
Җир биргәннәр барысы Җиргә кайта –
Җирнең уе – бары бәрәкәттә.

Җирнең уе бары Матурлыкта,
Калганнары тора үзебездән.
Матур яшәр өчен Хак Тәгалә
Һәммәсен дә салган күңелебезгә.

Тик без сукыр, чукрак кеше сыман,
Кайда нәрсә ята, шуны эзләп,
Тик йөрибез шунда әйләнгәләп,
Бәхет кошын тотмак булып тизрәк.

Ә ул кош бит сөйми комсызларны,
Көнчеләрне читтән урап уза.
Кояш кебек җылы нурың сипсәң,
Каршыңдагы гөлгә килеп куна.

Табигатьтә бар нәрсә дә ачык –
Йөрәкләре ачык кешеләргә.
Бәхет-шатлыклары баштан ашкан
Табигатьнең үзе ишеләргә.

* * *

Шатлыкларың, кайгыларың өчен
Мең-мең рәхмәт, Раббым!
Шатлыкларың – җәннәт,
кайгыларың – тәмуг,
Һәммәсен дә бу дөньяда таптым.

* * *

Куркытмагыз әле тәмуг белән,
Тәмугларның иң хәтәре Җирдә.
Җәннәттән баш тарткан исәрләрнең
Тәмуг уты яна күңелендә.

* * *

Җырларың ник моңлы? – дип сорыйлар.
Мин – авылда үскән баламын.
Моңнарны мин сызылып таң атканда
Кошлар сайравыннан аламын.

Көз сулышы, диләр, җырларыңда,
Күбрәк язны җырла син, диләр.
Көзләр миңа язны якынайткан
Җырлар алып килә – белмиләр.

Сулар бездә салмак, уйчан ага,
Уйчанлыгым, бәлки, шуннандыр?
Чишмә җыры, моңлы бер көй булып,
Күңелемә кереп тулгандыр.

## БОЗЛЫ ТАУЛАР ИЛЕНДӘ

Кояш һәм Боз. Җылы. Салкын.
Алар монда янәшә.
Яле, менеп кара, диеп,
Бозлы таулар эндәшә.

Алар монда шундый да күп –
Бу карлы-бозлы таулар.
Кайдан иңгән бу Боз иле –
Кем аңлатыр, кем аңлар?

Бозлар суга әйләнәләр,
Сулар боз була ала.
Ә биредә карлары – кар,
Бозы боз булып кала.

Монда якты, карлар – энҗе,
Хәтта күзләр чагыла.
Туп-турыдан карый Кояш
Җирнең бозлы тавына.

Караса да, эреталмый
Карларын да, бозын да.
Аңлашылмас нәрсәләр күп
Бу Яшәеш кырында...

## ТАУГА МЕНЕП БАРАМ...

Ял да итми
Тауга менеп барам,
Үзенә тарта Кояш нурлары.
Упкыннарга карамаска тырышып,
Гел үрлисе килә югары.
Ә упкыннар,
Адым саен очрап,
Хәвефле шом сала күңелгә,
Әй куркыныч була
Кайчакларны,
Бар да беткән төсле күренә.
Таулар бигрәк биек,
Баш әйләнә,
Югарыга карыйм куркынып.
Ә шулай да
Гел үрлисе килә биеккәрәк,
Кояш нурларына тотынып.

## ТОРМЫШ

Елата да белә тиктән
Йөзен бозып йөргәннәрне.
Юата да белә үзе
Көя белеп көйгәннәрне.

Тормыш бит ул сөя икән
Бары үзен сөйгәннәрне.

## КЫЗЫЛ КАУРЫЙ

*Сажидә Сөләйманова*
*истәлегенә*

Күктә салават күпере –
Күземне ала алмыйм.
Син яраткан ялкын төсен
Таныйм мин анда, таныйм.

Бер сандугач идең илдә,
Аккош идең күлләрдә...
Кызыл каурый булып очты
Гомерең искән җилләрдә...

## ЮЛДА МИН...

Һич тә гамьсез яшәмимен –
Гомер буе уйда мин.
Әле анам, әле балам...
Һәммәсенә мин кирәкмен,
Гомер буе юлда мин.

Юлым озын. Соң сулышым
Кайда булыр, белмимен.
Тынгысызмын, һич хаксызга
Рәнҗетелгән ак җаннарның
Хакын хаклап йөримен.

Юк, мин һич тә уйсыз түгел,
Әмма уйдан бөгелмим.
Яшәвемнең чын мәгънәсен
Уйлы юлда, уйлы җырда,
Уйлы моңда күрермен.

* * *

Еларлык сәбәп болай да
Ята ул дөнья тулып.
Үтик кешеләр җанына
Дәртле, моңлы җыр булып.

Үзен генә яратканнар
Елата кешеләрне.
Нурлар өләшик дөньяга,
Яктырып яшик әле.

Кызганып карамасыннар,
Сокланып карасыннар,
Сихерләнеп караган күк
Сандугач баласына...

* * *

Алсуланып пешкән алмага
Әйләнеп тә хәтта карамам,
Усал ният белән йөрсәләр.

Хакыйкатьнең ачы баланын
Татлы җимеш диеп кабармын,
Изге ният белән бирсәләр...

* * *

Сәер бу уйлар йомгагы –
Тормыш йомгагы төсле.
Тәмам чуалып бетә дә,
Һич табып булмый очын.

## ЯРАТЫГЫЗ МИНЕ ШУШЫ КИЛЕШ!

Хәйлә-мәкер күрсәм берәрсендә,
Гамьсез генә карап торалмыйм.
Хаклык дәрьям-елгам туры ага,
Мин юлыннан кире боралмыйм.

Ялган белән чынлык арасына
Хәйлә күперләре салалмыйм.
Яратыгыз мине шушы килеш –
Мин үземә каршы баралмыйм.

* * *

Чынбарлык ул шундый:
Тәнгә генә түгел,
Сала тора җанга яралар.
Мин бәхетле,
Кагылу-сугылудан
Хет бер җанны алсам аралап.

* * *

Кояшлы утраулар эзләп,
Ераклардан килешем.
Һәр мизгелдә сизеп торам
Дусның йөрәк тибешен.

Миңа дусның: «Мин монда!» –
Эндәшүе кирәкми.
Иң нечкә кыллар бәйләгән
Икебезнең йөрәкне.

## ИҢ ЗУР БӘХЕТ*

*(Жыр)*

Жаның-тәнең биреп эшләр эшең булса,
Эштән сине сагынып көтәр кешең булса,
Иң зур бәхет менә шул ул дөньяларда.

Сары сагыш йөзләреңне киптермәсә,
Бала-чагаң сиңа хәсрәт китермәсә,
Иң зур бәхет менә шул ул дөньяларда.

Баш очында балкып торган күгең булса,
Алда сине көтеп торган үрең булса,
Иң зур бәхет менә шул ул дөньяларда.

Анаң кебек газиз туган җирең булса,
Җылы өең, өйдә якты түрең булса,
Иң зур бәхет менә шул ул дөньяларда.

* * *

Табигатьне, имеш, үзгәртәбез,
Рәхимлекләр, имеш, көтмибез.
Син көчлесең, әмма без тагын да
Куәтлерәк, диеп үртибез.

Тауларны да, имеш, күчерәбез,
Елгаларны кире борабыз...
Тарту көчен җиңеп, әллә кая –
Галәм киңлегенә чыгабыз.

Сораулардан урман алдыбызда –
Шул урманны көчкә ерабыз.
Үзебез балта чапкан яшь ботакта
Чак-чак кына элэгеп торабыз...

---

* Фәрит Хатипов көе.

## ҖЫРЫМ*

*(Җыр)*

Минем җырым – язгы ләйсәннәрдә,
Минем җырым – Кояш нурында.
Минем җырым бөре булып тула
Кушкаенның җылы куенында.

Минем җырым – яшел үзәннәрдә,
Минем җырым – тугай-болында.
Минем җырым борыла-сырыла аккан
Инешемнең көмеш җырында.

Минем җырым – кошлар сайравында,
Минем җырым – бөдрә талларда.
Минем җырым эзләп табар мине,
Китсәм дә мин әллә кайларга.

Минем җырым дөрли йөрәгемдә,
Күңелемнең чыңлый түрендә.
Минем җырым – Сагыш, Моң һәм Сөю,
Яшел яшьлек – Яшәү турында!

* * *

Туры юлым таш яра, дип,
Алга карап барган көнем.
Туры әйткән өчен какмас
Илем-көнем, үскән җирем.

---

* Әнвәр Бакиров көе.

# ӘТНӘМ – ТУГАН ЯККАЕМ*

*(Җыр)*

Хәтфә таулар, яшел үзәннәрем,
Җир җиләге пешкән болыннар...
Туган якта мине былбыл иткән
Үзем генә белгән җырым бар.

К у ш ы м т а:

Әй, Ашытым, мин бит гашыйкмын
Бормаланып аккан суыңа.
Әтнәм минем – сөеп туймас илем,
Дәртле моңнар өстә җырыма.

Ничек онытыйм, еракларга китеп,
Кояшка тиң Әтнә халкын мин?
Түзә алмам сагыну сагышына,
Кошлар булып очып кайтырмын.

К у ш ы м т а.

Иркәләнеп назлы җилләреңдә,
Буй үстергән моңлы балаң мин.
Ташлый алмыйм яшел ярларыңны,
Гомерлеккә синдә калам мин.

К у ш ы м т а.

---

* Луиза Батыр-Болгари көе.

## САГЫНУ ДӘРЬЯЛАРЫ ТИРӘНДЕР...

Өянкеләр инде уянгандыр,
Бөреләре тулып барадыр.
Бала-чага ерган канаулардан
Кар сулары гөрләп агадыр.

Яз кошлары диңгез аръягыннан
Яңа җырлар алып килгәндер.
Яшь каеннар шуны ота булыр...
Тау башлары яшел чирәмдер.

Аксыл-зәңгәр күкләр ап-аяздыр,
Яңа юган кебек булгандыр.
Матурланган, тагын яшәргәндер,
Киңәйгәндер авылым урамы.

Тау башлары яшел чирәмдер...
Кырлар бәрхет күлмәк кигәндер.
Алар, бәлки, мине сагына булыр,
Кайтмый калмас, кайтыр, диләрдер...

Сагыну дәрьялары тирәндер...

## КЕМНӘР ӘЙТТЕ ӘЛЕ...

Кемнәр әйтте әле сине,
Кем кимсетте,
Ачыла алмый калган гөл, диеп?
Гафу сорыйм
Шул адәмнәр өчен,
Җиргә кадәр синнән иелеп.
Бакчаларда йөрдем,
Күпме гөлләр күрдем,
Синнән матур гөлне тапмадым.
Алыштырмам
Гөлләр диңгезенә
Чык бөртеге кунган яфрагың...

# КАРА ӘЛЕ ТУТЫРЫП КҮЗЛӘРЕМӘ...

Кара әле тутырып күзләремә,
Күзләреңне миннән яшермә.
Үткәннәр бит алай ерак түгел,
Син хәтерлә әле, хәтерлә.

Артта калган еллар хатирәсен
Капламаган әле томаннар.
Өметләр бит әле сүрелмәгән,
Онытылмаган әле хыяллар.

Аңлыйсыңмы, бар дөньяны онытып,
Сөеләсем килә, сөясем.
Күзләреңдә боз салкыны түгел,
Җылы кояш килә күрәсем.

Кара әле тутырып күзләремә...

* * *

Ак болытлар, күрче, нинди нәфис,
Ул болытлар кая йөзә икән?
Күңелемнең ак болыттай чагы –
Синең күңел шуны сизә микән?

Акчарлаклар оча җайлап кына,
Суга тиеп китә канатлары.
Дәшми генә ап-ак шул кошларга
Карап торыйк әле, яратканым.

Ак төнбоек яшь кәләштәй бүген,
Боек диеп кемнәр әйтер аны?
Күңелләрдән соңгы сагышларны
Юып китсен суның дулкыннары.

Йә төнбоек, йә акчарлак булып
Дулкыннарга без дә куныйк әле.
Дөнья бүген ап-ак, якты бигрәк –
Дәшми генә карап торыйк әле...

* * *

Чәчләремнән назлап иркәләгәч,
Ефәк җилгә
Серем ачкан идем.
Аңламыйча калмаслар ич, диеп,
Горур тауларга да
Дәшкән идем.
Уйларымны кемгә сөйләргә
Белми ярсып йөргән көннәрдә
Серем чишкән идем
Алсу битле,
Нечкә билле нәфис гөлләргә.
Җилләр сиңа берни әйтмәгәннәр,
Биек таулар
Берни дәшмәгәннәр.
Гөлләре дә
Башын иеп торган...
Ничек яшәгәннәр алар,
Ничек яшәгәннәр?!

## САГЫШ*

*(Җыр)*

Яланнарда ялгыз йөрим,
Белмим ниләр кирәген.
Күңелемне моңнар сарган,
Сагыш тулы йөрәгем.

Яланнарда ялгыз йөрим,
Иеләм җирҗиләккә.
Бәлки, җиләк шифа булыр
Сагыш тулы йөрәккә?

Яланнарда ялгыз йөрим,
Тыңлыйм кәккүк тавышын.
Моңлы кошның җан авазы
Арттырадыр сагышым.

Яланнарда ялгыз йөрим,
Нишләтим бу сагышны?
Минем болай йөрүләрем
Ялгышыммы, язмышмы?

Яланнарда ялгыз йөрим,
Бетәрме бу сагышлар?
Ялгышлар бер төзәтелеп,
Кушылырмы язмышлар?..

* Алмаз Хәмзин көе.

# БИК ЯМАНСУ БУЛЫР ӘЛЕ БЕЗГӘ...*

*(Җыр)*

Кар-бураннар мәңге дулый алмас,
Тагын килер язлар әйләнеп.
Бик ямансу булыр әле сиңа
Якты язлар килгән мәлләрне.

Төшләреңә кереп йөдәтермен
Җәйге таңнар сызылып атканда.
Шәфәкъларга карап моңланырсың
Алсуланып кояш батканда.

Бик ямансу булыр әле сиңа
Алтын көзләр кергән мәлләрне.
Төшенерсең агачыннан кубып
Җиргә төшкән яфрак хәлләрен.

Карлар сыман, керфегеңә кунып,
Күзләреңә синең багармын.
Сагыш-моңга түзә алмам мин дә,
Күз яшьләре булып тамармын.

---

* Роза Мөхәтдинова көе.

## КЫШЛАРНЫҢ БУРАННАРЫ*

*(Җыр)*

Мәхәббәтең ялкынына
Чорнадың, урадың да,
Алып кереп киттең мине
Кышларның буранына.

Бәлки, сүнәр бураннарда,
Сүрелер, дигәнсеңдер.
Уралыр бураннарга да
Сыналыр, дигәнсеңдер.

Уралдым бураннарга да,
Сыналдым, сынатмадым.
Мин үзем дә югалмадым,
Сине дә югалтмадым.

* * *

Ачу,
    үпкә,
        рәнҗү,
            хәтер калу,
Хәтта нәфрәт кичеп,
Матур бер Гөл
Өскә калкып чыкты,
Битарафлык дигән
        бозны тишеп.

Сөенмисең ничек?!

---

* Ринат Бикбулатов көе.

## ТИК ҮЗЕМЧӘ ГЕНӘ

Җир бит матур төрлелеге белән,
Кабатланмый хәтта язлар да...
Тик үземчә мин яшәргә телим,
Тик үземчә генә янарга...

## МИНЕМ ӨЧЕН

Кем өчендер, бәлки,
　　син ямьсездер,
Холкың да...
　　җайсыздыр.
Кем өчендер
Син – хыялый, бәлки...
Күктән йолдыз чүпләүчедер.
Кем өчендер тагы
　　син юлаучы,
　　　　бер узгынчы бары...
Ә бит син –
　　　　падишаһ,
Минем күңелемнең падишаһы.
Син – минем
　　　　күз өстемдәге кашым,
Син – минем
　　　　канатым сыңары,
Минем аерылмас ярым.

* * *

Бер газапсыз тумый һичнәрсә дә,
Ә гүзәллек инде бигрәк тә.
Татлы газап аша сыгылып чыккан
Моңнар гына үтә йөрәккә.

## ТИК ҖЫР ГЫНА БУЛЫР ЮЛДАШЫМ

Язлар алып килер кышларым бар,
Ялкынланып янар күзләрем...
Чынга ашар хыялларым дәшәр,
Гел юлларда булыр күзләрем.

Көннәр-төннәр үтәр сизелми дә,
Шәфәкъларым таңга тоташыр.
Киләчәккә илтер юлларымда
Тик җыр гына булыр юлдашым.

## МИН СИНЕ ШУНДЫЙ САГЫНДЫМ*

*(Җыр)*

Мин сине шундый сагындым, –
Сизәсең микән шуны?
Ак бураннар урап алса,
Табарсың микән юлны?

К у ш ы м т а:

Син дә шулай сагына калсаң,
Карама җилләренә...
Җыр булып килеп керерсең
Наз тулы йөрәгемә.

Мин сине шундый сагындым, –
Күзләрем шуңа моңлы.
Айны болытлар капласа,
Табарсың микән юлны?

К у ш ы м т а.

---

* Луиза Батыр-Болгари көе.

## ЯКТЫРЫП КИТТЕ КҮҢЕЛЕМ...

Сихри дөнья ачтым бүген –
Синең күңел дөньясын.
Син бугай ул күңелемә
Ак нур булып тулгансың.

Яктырып китте күңелем,
Бәхеткә тарган сыман.
Кара көздә бер иртәне
Ап-ак кар яуган сыман.

## МАТУР БУЛАСЫМ КИЛӘ*

*(Җыр)*

Ай кызыдай ачык йөзле,
Матур буласым килә.
Җил-давылга бирешмәслек
Батыр буласым килә.

Җилдән дә җитез буласым,
Уңган буласым килә.
Дуслар сөенерлек матур
Тормыш корасым килә.

Син миңа шундый булырга
Булышырсыңмы, иркәм?
Син миңа шундый тормышны
Корышырсыңмы икән?

* Фасил Әхмәтов көе.

# ЧАЙПАЛЫРМЫН, ТҮГЕЛЕРМЕН...*

*(Җыр)*

Чайпалыр да, түгелер дә –
Чиләкләрем мөлдерәмә.
Сез гаеплəп карамагыз
Суларым түгелгәндә.

Кушымта:

Ай, чиләкләрем мөлдерәмә,
Суым җиргә түгелә.
Күңелләрем мөлдерәмә –
Сулар булып түгеләм.

Алмалы көянтәләрем,
Җиләкле чиләкләрем.
Чайпалырсың, түгелерсең,
Ут янса йөрәкләрең.

Кушымта.

Чайпалыр да, түгелер дә –
Чиләкләрем мөлдерәмә.
Сез гаеплəп карамагыз,
Суларым түгелгәндә.

---

* Луиза Батыр-Болгари көе.

# РӘХМӘТ СИҢА, БӘХЕТ КОШЫМ!*

*(Җыр)*

Җиргә аклык, пакьлек өстәп,
Ярый әле, син тугансың.
Күңелемне Сөю, Бәхет,
Шатлык белән тутыргансың.

Кушымта:

Рәхмәт сиңа, Бәхет кошым,
Бу дөньяга туган өчен.
Рәхмәт сиңа, күңелемә
Ак нур булып тулган өчен.

Син булганда, яшәү миңа
Җиңелрәк моңсу Җирдә.
Иң-иң якты йолдызым бул,
Китмә, китмә күңелемнән!

Кушымта.

* Дамир Рәфыйков көе.

## БӘХЕТ ӨЧЕН*

*(Җыр)*

Бәхет өчен күп кирәкми –
Гел янәшә барсын юллар.
Бәхет өчен күп кирәкми –
Минем куллар синең кулда,
Синең куллар минем кулда.

Бәхет өчен күп кирәкми –
Артта калсын ап-ак эзләр.
Бәхет өчен күп кирәкми –
Минем күзләр синең күздә,
Синең күзләр минем күздә.

Тормыш – мизгел, бары мизгел,
Әллә ниләр өмет итмә.
Ахыргача бергә булсак,
Минем өчен шул да җитә,
Бәхет өчен шул да җитә.

Безнең урамда да бәйрәм булыр,
Ап-ал таңнар атар,
Җырын, моңын чорлар чоңгылында
Югалтмаса татар.

* Рөстәм Вәлиев көе.

* * *

Күктән йолдыз булып атылам,
диден,
Аяк астында бәллүр савыт булып ватылам,
диден...

Ә нигә?
Болар берсе дә кирәкми миңа:
Күктән йолдыз нигә атылганын
беләм,
Бәллүр савыт нидән ватылганын
беләм.

Сүзләремне
йөрәк түрләреңә салсаңчы:
Күктән йолдыз булып атылганчы,
Бәллүр савыт булып ватылганчы,
Кеше булып кына калсаңчы!

Бүтән нәрсә миннән эзләмәгез:
Мин шигырьдән торам.
Кояш тулы күңелемнең йортын
Мин шигырьдән корам.

# АНАЛАР ЙӨРӘГЕ ҖЫЛЫСЫ

Берсен дә күпсенми ул ана –
Баласы биш булсын, ун булсын...
Барына гомергә җитәрлек
Аналар йөрәге җылысы.

Шунда ук сизә ул, йөрәгең
Аз гына тигезсез типсә дә.
Һаман да сабый шул баласы,
Утызга, кырыкка җитсә дә.

Йөзләгән чакрымнар еракта
Сагышлар буганда сулышын,
Җан керә балага – сизә ул
Чал Ана йөрәге җылысын.

Иң хәтәр минутта кешеләр
Исенә төшерә Ананы.
Аналар йөрәге җылысы
Иң олы афәттән аралый...

Берсен дә күпсенми ул Ана,
Баласы биш булсын, ун булсын...
Барына гомергә җитәрлек
Аналар йөрәге җылысы.

# БЕР ҮГЕТ

Ни файда бар эш эшләнгәч үкенүдән?
Ни фәтва бар арыслан күк үкерүдән?
Яфрак яргач, көзен барыбер корый, диеп,
Агачтагы бөреләрне үтерүдән?

Агачтагы бөре бит ул – синең җаның,
Дөресрәге, Аллаһының бер кисәге.
Хакың бармы аны җирдән юк итәргә,
Шул турыда бармы синең бер исәбең?

Ник җаныңны дөрләп янган утка салдың?
Өметсезлек томанына урап алдың?
Томан бит ул тирә-якка таралучан –
Бармы синең шул хакларда уйланганың?

Мин – ялгыз, дип зарланасың вә елыйсың,
Рәнҗүләрдән, үпкәләүдән һич туймыйсың.
Уйлап кара: үз халкыңның улымы син,
Әллә инде мин-минлекнең колымы син?

Уйлап кара: үзеңне нык яратудан
Тумый микән мондый уйлар, мондый зарлар?
Иң элек син бүтәннәрне аңлап кара,
Шул чагында бүтәннәр дә сине аңлар.

Сөю җитми синең җанга – мин аңладым,
Бөтен бәла – күңелеңнең тарлыгында.
Ир-егет бул: оныт, әйдә, үпкәләрнең,
Рәнҗүләрнең бу дөньяда барлыгын да.

Бер игелек мең игелек булып кайтыр,
Өметсезлек шайтаннары читләп үтәр,
Төн карасы эреп бетеп, таң сызылыр,
Өр-яңадан туар җаның, бәйрәм итәр.

# КИТҮ

*Әмирхан ага Еники истәлегенә*

Күзегездә мөлдер-мөлдер яшь күрәм:
Нигә болай кайгырасыз, дусларым?
Мин бәхетле юлчы булдым дөньяда –
Үземнән соң калдырмадым дошманым.

Шатлыкларын, аз булса да, күп күрдем,
Кайгыларын, күп булса да, чүп күрдем.
Хәсрәтләргә баш имәдем, сынмадым,
Хак Тәгалә сынаулары, дип йөрдем.

Кеше шулай яратылган – еш кына
Тойгылары акылына баш була...
«Нишләп болай?», «Нигә болай?» дип йөри ул,
Шуннан инде күзләренә яшь тула...

Ә мин үзем, – сез бик яхшы күрдегез, –
Акылымны хисләремә баш иттем.
Хисләремне йөгәнләдем, ә мантыйкны
Күз өстендә, әйе, әйе, каш иттем.

Бәлки, шуңа күрәдер дә бу Җирдә
Шактый гына яшәлгән ич, яшәлгән.
Әллә ничә күңел кошым очырдым
Васыять итеп мин халкыма, яшьләргә.

Шуңа күрә һич үкенмим бу Җиргә
Килүемә, яшәвемә, китүгә.
Матур итеп яши белгәч дөньяда,
Кирәк инде матур итеп китү дә...

# НИГӘ БОЛАЙ?

Ак һәм Кара бергә очрашканда,
Күзләремә яшьләр килеп тула.
Җанны телә һаман бер үк сорау:
Нигә болай корылган соң дөнья?
Нигә болай корылган соң дөнья?

Ник туктатып булмый мизгелләрне –
Вакыт дигән елга кая коя?
Ник ашыгып килә соры көзләр?
Нигә болай корылган соң дөнья?
Нигә болай корылган соң дөнья?

Гел сагыштан яралганмы җиһан –
Нигә җырлар моңлы булып туа?
Кемнәр бәйләр йөрәк яраларын –
Нигә болай корылган соң дөнья?
Нигә болай корылган соң дөнья?

Әллә бары Шагыйрь иңнәренә
Дөнья үзенең яшьле йөзен куя?
Сулкылдата җанны бер үк сорау:
Нигә болай корылган соң дөнья?
Нигә болай корылган соң дөнья?

## БИК САГЫНАМ, ӘНКӘЙ, МИН СИНЕ

Сулар сибеп гөл үстергән кебек,
Назлап-сөеп кенә үстердең.
Җылы, якты Кояш кебек булдың, –
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.

Төшкә кереп, бәгырьләрне телдең,
Күзләремә энҗе яшь элдең.
Тирән икән сагыш дәрьялары, –
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.

Берни дә юк Җирдә мәңгелек, дип
Юатмакчы булам үземне.
Сүзләр җитми, күздә яшем кипми, –
Бик сагынам, әнкәй, мин сине.

## АНА СҮЗЕ

Үпкәлисең кайчак, киңәш бирсәк,
Өйрәтәсез, дисең, туктамый.
Өйрәтәбез, үстердек бит сине,
Озын төннәр буе йокламый.

Сез анысы бездән акыллырак,
Безнең өстә – еллар тузаны.
Сезгә кайчан акыл керә, диеп,
Тормыш безне мең кат «кыйнады».

Ә сез яшәмәкче кыйналмыйча,
Койрыкларны сыртка салмакчы.
Авырлыклар күрми генә, бездән
Акыллырак булып калмакчы.

Алай булмый, бала, алай булмый,
Җирдә тәртип, ай-яй, кырыс ул.
Җиңәм дисәң киртәләрне, бала,
Катыдан да каты корыч бул!

Кануннарны үтә сукранмыйча,
Сынауларда бирмә билеңне.
Кыйналганнар сүзенә колак салсаң,
Җиңелрәк булмас идеме?..

## ЫШАНДЫР!

Йөрәгемдә ут кабыздың,
Үлеп яратам, дидең.
Янып көлгә калсам калам,
Үземә каратам, дидең.

Кабынгач та сүнәр булсаң,
Кирәкми януларың.
Нигә күңелгә тияргә
Җилләнеп-давылланып?

Кабынгач та сүнәр булсаң,
Тимә син күңелемә.
Ышандыр мине дөньяда
Берүзем түгелемә.

Ышандыр мине дөньяда
Чын сөю барлыгына.
Кояшым-аем итәрмен
Мин шундый ярны гына.

## ЕЛМАЕП ТОР ЯННАРЫМДА

Оныт җирдә бозлар барын,
Болытлар барын оныт.
Елмаеп тор яннарымда
Алтын Кояшым булып.

Оныт бураннар барлыгын,
Давыллар барын оныт.
Йөзеп кенә кил каршыма
Ап-ак аккошым булып.

Оныт җирдә сагыш барын,
Үпкәләр барын оныт.
Очып кына кил яныма
Язгы күбәләк булып.

Салкын җилләргә юлыгып,
Әгәр дә калсам туңып,
Алма миннән күзләреңне,
Карашың белән җылыт.

Кулларың алма кулымнан,
Җирдә ни барын оныт.
Елмаеп тор яннарымда
Алтын Кояшым булып.

* * *

Кеше кайгысына кайгыру ул
Әллә ни зур егетлек түгел.
Кеше шатлыгына кайгырма син –
Үзеннән дә ныграк сөенә бел!

## БЕЗ ИКЕБЕЗ ПАР КЕБЕК...

Нигә чыктың юлларыма,
Әйтер сүзең бар кебек?
Ник карадың күзләремә,
Өзелеп сөйгән яр кебек?

Сүзең булгач, ник әйтмәскә,
Җаен туры китереп?
Гел тирәмдә әйләнәсең,
Өзелеп сөйгән яр кебек?

Мөлдер-мөлдер ике күзең,
Анда сагыш бар кебек.
Нигә карыйсың тилмереп,
Өзелеп сөйгән яр кебек?

Әйт сүзеңне, йөрмә инде
Явалмаган кар кебек.
Күңелкәем шулай сизә –
Без икебез пар кебек.

* * *

Каргый күрмә караңгыны –
Төн булмаса, көн бармы?
Аклы-каралы җиһанда
Бар нәрсә парлы-парлы.

Каргый күрмә караңгыны –
Яшәү сиңа ят булыр.
Шәмең кабыз да юлга чык –
Кара төнең ак булыр.

* * *

Нишләп андый булмаганмын,
Нигә мондый булганмын? –
И үкенә адәми зат,
Белми нигә туганын.

Атлаган саен сөрлегә,
Егыла, тагын тора.
Күзләре тулы сагыш-моң,
Үзе елмайган була.

Мин бүтәнчә яшәр идем,
Кабат Җиргә туалсам,
Дип юана адәм улы –
И бергатлы, сабый җан...

Беребезне беребез елатырга
Без бигрәкләр оста.
Ә бит гомер үтеп бара –
Гомер шундый кыска.

Беребезне беребез юатырга
Табылмый бит ара.
Ә бит гомер шундый кыска –
Гомер узып бара.

* * *

– Җәйләр кыска, кышлар озын булды,
Салкыннары булды бихисап...
– Андый чакта, җилкән җилгә куй да,
Күңелеңдә як син зур учак...

## ЯЛКЫН ТЕЛЕ

Җан – тынгысыз,
Дөрләп янган учак –
Нидер эзләп
кукка үрелә.
Ни эзли ул,
ни күзәтә өстә,
Аңа күктә ниләр
күренә?
Кеше күзе күрми,
Күңел күзе күрә,
Җанның «күзе» үткен –
Төн пәрдәсен тишә,
Җирдә чишелмәгәннәрне
чишә.
Ялкын теле
күккә үрелә...

# ӨЙРӘН...

Нигә күккә ашкынасың,
Җиреңә төш, тилебаш!
Нигә өскә үрелергә,
Җирдә яши алмагач?

Биек күккә үрелгәнче,
Өйрән Җирдә яшәргә.
Өйрән җирне сукаларга,
Тырмаларга, чәчәргә...

Өйрән игелек кылырга,
Чәчкәнеңне урырга.
Тормыштагы ваклыклардан
Өйрән өстен торырга...

Шул чагында Күкләр сине
Үзләре үк күрерләр, –
Яннарына дәшәр өчен
Ап-ак канат бирерләр.

# ИШЕТЕРМЕ ХОДАЙ?

Өермәдәй ду китердек Җирне,
Әллә ниләр яклап сугыштык.
Ялган вәгъдәләргә ышандык та,
Матур тормыш Җирдә «корыштык».

Җир күкрәген рәхәтләнеп издек,
Тәмам вәхшиләрчә кыландык:
Безгә тормыш биргән Ана бит бу,
Болай килешми дип тормадык.

Нәрсә эшләгәнне белештерми,
Эчә торган суга төкердек.
Егылыплар төшәсене белми,
Арысландай Айга сикердек.

Алда өч юл ятканлыгын белдек,
Тик... һәлакәт юлын сайладык.
Үзебезгә хөкем оештырдык,
Аералмый хактан ялганны.

Хәзер менә күңелләрдә курку,
Башлар аска таба иелгән.
«Йа Ходаем, сакла, ярлыка!» – дип,
Дога пышылдыйлар иреннәр.

И беркатлы, яши белми торган,
Адашкан җан – кеше туганым!
Беләсең бит ниләр кылганыңны –
Ишетерме Ходай догаңны?!

* * *

Байлыкка мин гомер кызыкмадым,
Зур сарайлар миңа ят булды.
Яши белмәс идем мин аларда,
Табынганым фәкать Хак булды.

Зур сарайлар мине изәр иде,
Ә мин ирек, хөрлек яратам.
Үзем җырлап йә дусларым аша
Хөрлек җырын Җирдә таратам...

Мин патша да, ханбикә дә түгел,
Гади Җирнең гади баласы.
Үзем кебек гади балаларның
Гап-гади бер газиз анасы.

Зур байлыклар килсен дип теләмим,
Байлык боза бик күп кешене.
Байлык өсте байлык кирәк була,
Киң ачыла нәфес ишеге.

Алдын-артын карамыйча, кеше
Кереп китә ачык ишектән.
Күрмәс була күзе, саңгыраулана,
Вөҗдансызны үзенә иш итә.

Ә минем бит килә бу җиһанда
Саф намусым белән каласым.
Җирдән киткән чакта үзең белән
Тагын инде нәрсә аласың?!

Мин бит Җирнең гади баласы.

## БЕЗ – КЕШЕЛӘР...

Исән чагында
И сүктек, и сүктек,
Тетмәләрен теттек,
Хәтта үзебез арып беттек.
Якты дөньяларны
калдырып киткәч,
Җирне ятим иткәч
(Җир тәнендә
тагын бер күзәнәк үлде!),
И кызгандык,
И еладык,
Һәм аптырап калдык:
Ул бит шундый да
Әйбәт булган икән,
Күңеле
тоташ моңнан торган икән...
Элегрәк нигә күрмәгәнбез?
Без аңарда
нәрсә эзләгәнбез?..

Без – кешеләр –
Нигә шундый икән?
Без – кешеләр! –
Нигә кыргый икән?!

## КӨТӘМ...

Бөтерелеп, шаулап алдылар да,
Белмим, никтер тынып калдылар.
Нинди көчләр тынгы белмәс җанны
Тынлык упкынына салдылар?..

Көтәм хәзер шаулы дулкыннарның
Күңел-ярга кабат какканын.
Өметләнеп... түгел, җирсеп көтәм
Алсуланып таңнар атканын.

* * *

И хыялый, тиле бала,
Ник текәлдең дөньяга?
Ни күзлисең киң дәрьяда,
Ни югалттың син анда?

Ни югалттың зәңгәр күктә –
Кояшнымы, Айнымы?
Елмаюың кая китте,
Ник йөзләрең кайгылы?

Тау-тау шашкын дулкыннарда
Югалтма үз-үзеңне.
Хәзергә үз урынында –
Кояшка куй йөзеңне.

* * *

Кайгы – озын, шатлык – мизгел,
Таңда чәчкә аткан гөл.
Кайгыларның бетәсе юк,
Мизгелләрнең кадерен бел.

* * *

Язмыш какса, мин бигрәкләр
Бәхетсез, дип үртәлмә.
Бүген матур итеп яшә –
Матур булыр иртәгәң.

## АП-АК КӘГАЗЬ. КАЛӘМ. КАРА

Күктә – Кояш, җирдә – гөлләр.
Язлар әллә үтеп бара?
Сабыр гына көтеп ята
Ап-ак кәгазь. Каләм. Кара.

Җирдә – давыл, күктә – шавы.
Дөнья кая таба бара?
«Җаның бармы?» – диеп сорый
Ап-ак кәгазь. Каләм. Кара.

## НИШЛӘТӘСЕЗ ЙӨРӘКНЕ?

Алтын битлек, алтын читлек –
Кемгә нәрсә дөньяда.
Таш йөрәкле гамьсезләрнең
Кайгыларын җил ала –
Илтеп дәрьяга сала.

Чын йөрәкнең ни гаебе?
Ул бит гамьсез булалмый.
Алтын битлек тә киялмый,
Үз-үзен бикләп куярга
Алтын читлек коялмый.

Йөрәк мескен нишләсен соң? –
Бар давылларга ачык.
Нишләтәсез сез йөрәкне,
Әй, дөньяның сукырлары,
Ярасын ачып-ачып?!

## УЙЛАМА, ДИСЕҢ...

Уйлый күңелем төрлесен...
*Халык җырыннан*

Уйлама, дисең, уйлама, –
Гөлләр үсә тирәндә...
Гөлләр дә күзгә күренми –
Кердем, ай-һай, тирәнгә!..

Уйлама, дисең, уйлама,
Уйлама бик тирәннән.
Нишлим – йөрәк дулкыннарым
Бик тирәнгә көйләнгән...

## КОЯШКА!

Нур сибәргә диеп килгәч Җиргә,
Нигә Кояш кебек булмаска?!
Җитәр микән буем,
Җитмәс микән буем? –
Мин үреләм әле Кояшка!
Кояшка!
Кояшка!
Кояшка!

Җылытырга диеп килгәч Җирне,
Нигә Кояш кебек булмаска?!
Җитмәсә дә буем,
Җитми калмас уем,
Мин үреләм әле Кояшка!
Кояшка!
Кояшка!
Кояшка!

* * *

Шулкадәр дә моңсу – йөрәккәйләр
Өзелергә торган яфрак төсле.
Уйланганың бармы шул хакларда:
Нишләтәсең Кешене, әй, Кеше?!

Кеше хәлен аңламаган әйтер:
«Яши бит ул көлә-көлә генә...»
Яшь аралаш көлү бит ул.
Кеше
Үз хәлләрен үзе генә белә...

* * *

Кайчакларда, артык йомшап китеп,
Туйдым синнән, дөнья, дип әйтсәм,
Рәнҗемәгез миңа, ак каеннар,
Үпкәләмә миңа, Җир-әнкәм!

Үпкәләмә миңа, якты Кояш,
Мул итеп сип Җиргә нурларың.
Сине дә бит кайчак болыт каплый,
Дөнья куя кайчак болганып.

Мин дә менә синең төсле инде –
Бер елмаям, тагын моңаям...
Бу – вакытлы болыт кына бары,
Үтәр әле, диеп юанам...

## АҢЛЫЙ АЛМЫЙМ

Бу ялгышлар бүтән кабатланмас,
Бу утларга бүтән кермәм, дидем...
Атылып кердем утның уртасына,
Янар өчен сәбәп эзләп йөрдем.

Бу суларга бүтән төшмәм, диеп
Кабатладым үземә гомер буе.
Әле утка, әле суга кердем,
Ут белән су янәшәмдә булды.

Сәбәпләрен эзләп ялгышларның,
Әйләнәм дә үткән юлга карыйм.
Күп нәрсәне аңлыйм мин тормышта,
Тик үземне генә аңлый алмыйм...

## ЫШАНЫГЫЗ!

Хаталардан һичкем хали түгел,
Ялгышты, дип, ялгыз итмәгез.
Бураннарда калып, юлдан язсам,
Аерылды, дип, ташлап китмәгез.

Гөнаһларым булса, шелтәләгез,
Юлларыма борылып карармын.
Сүнә төшсәм, җан өрегез миңа –
Ялкынланып тагын янармын.

Үпкәләшкән чаклар булмас, димим,
Болгана да сулар, тона да...
Һәр йөрәктә хаклык уты яна,
Мин ышанам менә шуңарга.

Юк-бар үпкәләүләр онытылыр,
Хыянәтне генә кичермәм.
Соңгы сулышкача мин сезнеке,
Ышаныгыз миңа, кешеләр!

## ӨМЕТ

Өмет белән килә кеше,
Өмет белән яши Җирдә.
Үлгәндә дә башта үзе,
Аннан гына өмете үлә...

* * *

Теләсә ни уйласыннар минем хакта, –
Үзем беләм «кара йөрәк» түгелемне.
Намусым да, вөжданым да, шөкер, исән,
Беркем, берни төшералмас күңелемне.

Теләсә ни уйласыннар минем хакта, –
Үзем беләм түбән җанлы түгелемне.
Алтыннарга сатылмастай җаным исән –
Беркем, берни төшералмас күңелемне.

Сөйләсеннәр, дуласыннар туйганчы бер, –
Ә мин беләм көлеп кенә йөреремне.
Диңгездәге таш кыядай нык торамын –
Беркем, берни төшералмас күңелемне.

Җырлап яшим, көлеп яшим, бәхет санап
Бар нәрсәне якты итеп күрүемне.
Төн артыннан көн туасын беләм ич мин –
Беркем, берни төшералмас күңелемне.

## ТАҢГА КАРАП

Юлларымның очы кайда – белмим,
Таңга карап киләм.
Эштән чыгып арган чакларда да
Таңга карап көләм.

Күңелемә ак өметләр тулган,
Кояш – минем дустым.
Мин эзләгән кеше юлларыма
Таңга карап чыксын!

## НИ ДИЯРЛӘР ИКӘН?

Ни мәңгелек икән җир йөзендә? –
Бар да бетә, бар да югала...
Кеше килә, яши. Китеп бара,
Ни кала соң аннан, ни кала?

Дан, дәрәҗә, байлык, югары пост –
Вакытлылар бар да дөньяда.
Мәңге китмәскә күк килгәннәрдән
Ни кала соң Җирдә, ни кала?

Йолдыз кебек атылып үтә гомер,
Җир өстенә түгелеп моң кала.
Әйткән сүзләр, кылган эшләр кала
Хатирәләр булып дөньяга.

Тормыш күкләрендә эз калдырып,
Йолдыз кебек атылып бер үткәч,
Нәрсә калыр бездән кешеләргә?
Ни диярләр икән без киткәч?!

## ХӨКЕМДАР

Кайчакларны, ят бер кеше булып,
Мин үземә читтән карап торам.
Хисап биреп кылган гамәлләргә,
Яхшы-яманлыкны барлап торам.

Игелек өчен мактап куям «мин»не,
Ялгыш адым өчен тетеп салам.
Әкрен-әкрен шулай Яхшылыкка
Якыная бара бугай арам...

* * *

Боздай карашларны күрдем,
Чыгармадым яшемне.
Әрнүемне, сагышымны
Күңелемә яшердем.

Бер җылы күз карашыннан
Күңел-елгам ташыды.
Бер җылы сүз иелдерде
Иелмәстәй башымны...

## КҮҢЕЛ КҮГЕ

Онытылмастай рәнҗү-әрнешләр дә
Бер онытылыр, вакыты килеп җиткәч.
Сагыш урынын шатлык биләп алыр,
Күз елмаер, йөзләр булыр көләч.

Күңел күкләренә кояш әкренләп
Балкып торган салават күпере салыр.
Тик... шул күкнең бер читендә менә
Нәни генә болыт эленеп калыр...

* * *

Зарларыңны җилгә сөйлә:
Җил – иң якын сердәшең.
Авыр чакта тик ул гына:
«Нихәл?» – диеп эндәшер.

Беркемгә чишмәс сереңне,
Ялан өстенә сибәр...
Дусларыңа түкмә зарың,
Җилләргә генә сөйлә!..

# КИҢӘШ

Иң-иң нечкә кылны
Ничек кырыкка ярасын
Кылычтан сора!

Гомер буе
Ничек яшь булып каласын
Ылыстан сора!

Күккә үрелә-үрелә
Ничек ялкынланып янасын
Учактан сора!

Утсыз калган чакта
Ничек очкын чыгарасын
Чакматаштан сора!

Җил-давыллы
Шушы җир йөзендә
Ничек итеп җылы,
Якты булып каласын
Кояштан сора!

* * *

Көн белән төн чиратлашып тора,
Яхшы-яман белән дөнья тулган.
Яхшысын да, яманын да татып,
Берәм-берәм кешеләр дөнья куя.

Мәхәббәт һәм нәфрәт ялкыннары...
Кеше йөрәгенә бар да сыйган.
Җир йөзендә бары бер нәрсәгә –
Ялгызлыкка күнегеп булмый сыман.

* * *

Мин туганмын сугыш беткән елны,
Күрмәдем мин зур давылның үзен.
Күрдем бары эзсез юкка чыккан
Улын көтеп сулган ана йөзен.

Шул афәтне, гарасатны җиңгән
Батырларның күрдем кайберләрен...
Бик күбесе яуда башын салган,
Калган безгә бары каберләре.

Биш почмаклы йолдыз нуры калган,
Мәңгелек ут калган мәйданнарда.
Гомер сүнмәс сагыш уты калган
Йөрәкләрдә дөрләп гел янарга.

Хәтер калган, хатирәләр калган,
Тол-ятимнәр калган дөнья тулып...
Без калганбыз менә, егылмыйча,
Шул афәткә утлы нәфрәт булып!

## ҖИРНЕ САГЫНЫП

Күккә мендем,
Йолдызларга җиттем –
Йолдыз буранына уралдым.

Сагындым да,
Кире Җиргә төштем –
Уйлар урманында югалдым...

* * *

Мин яратам утны, суны, җирне...
Мин яратам бөтен дөньяны.
Мин беләмен бер яшь тамчысына
Галәм кадәр шатлык сыйганын.

Мин гашыйкмын барча кешеләргә,
Мин яратам бөтен дөньяны.
Мин беләмен бер яшь тамчысына
Дөнья кадәр сагыш сыйганын.

Мин яратам җирдә ал гөлләрнең
Бар төсләрне үзенә җыйганын.
Шатлыклары-сагышлары белән
Кочагыма алам дөньяны...

* * *

Бу дөньяда бар да үз урынында –
Йөрмә генә җуеп гамеңне.
Яшәү миңа нинди төстә булса,
Ничек булса, шулай кадерле.

Бу дөньяда бар да үз урынында –
Кайгы-хәсрәт, шатлык-сагышлар...
Мәрхәмәтсез булды диеп миңа,
Зарланмыймын һич тә язмыштан.

Барына да әзер мин дөньяда –
Йөрмим җуеп яшәү гамемне...
Тормыш миңа нинди төстә булса,
Ничек булса, шулай кадерле.

# БЕЗНЕҢ ҖЫРЛАР НИНДИ БУЛЫР ИКӘН?

Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла...
*М.Җәлил*

Ябырылып яулар килә калса,
Зур сынаулар килсә ил башына,
Сыгылдырмас микән авырлыклар,
Күтәрә алырбызмы иңбашына?

Үлем каршысына көлә-көлә,
Җырлый-җырлый бара алырбызмы?
Чакматаштай очкын чәчрәтерлек
Олы көчне таба алырбызмы?

Җәлил җыры... Йөрәкләрне телә
Чит җирләрдә язган соңгы җырлар.
Кабынып өчен зур сынаулар кирәк,
Җырның юлы, ай-һай, нинди урау!

Безнең җырлар нинди булыр икән,
Үтеп керер микән йөрәкләргә?
Чит җирләрдә башны сала калсак,
Кайтыр микән урап еракладан?!

Безнең җырлар нинди булыр икән?..

## СОҢГЫ ЯФРАК*

*(Җыр)*

Яшим диеп күпме тартышса да,
Соңгы яфрагы да өзелеп төште. –
Сары җилләр сарылып, юаткандай,
Каен кызын иңнәреннән кочты.

Җил-давылда әгәр аумый калса,
Җан иңәр ул каен йөрәгенә;
Өмет тулы җырлы язлар килер,
Яшел җилләр сарылыр иңнәренә.

Бар да кайтыр, бар да кабатланыр, –
Шулай булачагын беләм ич мин.
Ник соң сагыш бәргәләнә җанда,
Өзелеп төшкән соңгы яфрак төсле?!

---

Ни булган бу Табигатькә,
Ни булган бу дөньяга? –
Йә кар катыш яңгыр ява,
Йә яңгырлы кар ява...

Ни булган бу Табигатькә,
Ни булган бу дөньяга? –
Батмаска чыкканмы кояш,
Елмая да елмая!..

* Әнвәр Бакиров көе.

* * *

Баш очында
Кара болыт булып
Кайгы эленеп торса,
Олы-кече хәсрәт,
Бер-бер артлы килеп,
Барыр юлын буса –
Кешегә,
Түземле бул, дибез,
Сабырлыкка өндибез.

Таш кыялар түзалмаслык
Җан әрнүдән
Эчләр сызса,
Гайбәт сүздән,
Ачу-нәфрәт,
Ялалардан
Йөрәк кызса –
Үз-үзебезгә,
Түземле бул, дибез,
Сабырлыкка өндибез.

Ә дөньяга,
Яшел Җиргә
Ябырылып давыл килгәндә,
Кешеләргә
Ни дияргә?
Шулай ук
Сабырлыккамы өндәргә?
Ни диярге
Кешеләргә?!

# КАЕННАРНЫҢ АК ЯКТЫСЫ*

*(Җыр)*

Күңелемә тулган моң-сагыштан
Ямансулап йөргән берчакны,
Килеп чыктым каен урманына, –
Каен урманнары яп-якты.

Күңелемә ак нур булып тулды
Каеннарның ап-ак яктысы.
Шушы аклык, шушы гүзәллекне
Ахыргача иде саклыйсы.

Көзге юлдан атлыйм акрын гына,
Моңсуланып шаулый яфраклар.
Ярый әле, җирдә каеннар бар,
Ярый әле, җирдә аклык бар!

Күңелемә ак нур булып тулды
Каеннарның ап-ак яктысы.
Шушы аклык, шушы гүзәллекне
Ахыргача иде саклыйсы.

* Рәшит Кәлимуллин көе.

* * *

Күз яшьләре ява Табигатьнең,
Ник сагышлы болай ул һаман?
Кургаш ява төсле йөрәкләргә –
Ник кайгыра болай Җир-анам?

Кайда калды тыныч, матур көннәр,
Килер микән алар тагын бер?
Күз яшьләрен сөртик Җир-әнкәнең –
Мин Кояшны үлеп сагындым...

## ХЫЯЛ УТЫ

Инде таптым, инде килеп җиттем,
Хәзер... хәзер генә дигәндә,
Йә биеккә менеп китә ул ут,
Йә каядыр чума, тирәнгә...

Нидер табып, нидер югалтабыз,
Без эзләргә инде өйрәнгән.
Тик очарга кирәк биектәнрәк,
Тик эзләргә кирәк тирәннән.

Йолдыз яна хыял уты булып,
Ә энҗеләр ята иң төптә.
Шуңа күрә кеше омтыладыр
Йә тирәнгә, яки биеккә...

* * *

Су буенда йөрим өзгәләнеп
Йөрәгемне телгән сагыштан,
Кыштыр-кыштырниләр серләшәсез,
Сез дә сагышлымы, камышлар?

Күге, суы соры. Йөрәгемдә
Сары камыш төсле сагыш бар.
Сагышларым сездә адаштырсам,
Ачуланмагызчы, камышлар!

* * *

Каен кызы ник боеккан?
Нигә сынган? Кем сындырган?
Нигә җирдә бәргәләнә? –
Бу кошчыкка ниләр булган?..

Һәр хәсрәте тереклекнең
Бәгыремә яра сала.
Юлга күпме яшьләр тама,
Гомер буйлап бара-бара...

Бар тереклек ялварышып
Минем күзгә карый төсле...
Кайгылардан аны йолып
Алыйм ничек, алыйм ничек?!

* * *

Әкрен генә менеп киләм
Язмышымнан – үремнән.
Алда үрләр генә түгел,
Таулар калкып күренә.

Рәхмәтлемен язмышыма –
Шулай булырга тиеш:
Алда биек таулар булып
Өмет торырга тиеш.

## МИН ГАШЫЙКМЫН...

Кояш җылы нурын суза җиргә –
Күз алдымда бөре уяна.
Сабый бала төсле гаҗәпләнеп,
Исем китеп карыйм дөньяга.

Тәрәзәмә бер кош килеп кунган,
Әй талпына инде, куана!..
Мин гашыйкмын шушы нәни кошка,
Мин гашыйкмын шушы дөньяга.

Юлга чыксам, юлым озын, чиксез,
Юлдашларым әйбәт – юлларда.
Мин гашыйкмын яхшы кешеләргә,
Мин гашыйкмын якты дөньяга.

Нинди гүзәл җирем – яшел бишегем,
Һич сокланып туймыйм мин аңа.
Сабый бала төсле гаҗәпләнеп,
Исем китеп карыйм дөньяга...

* * *

Шау-шулардан туеп,
Барын читкә куеп,
Гамьсез булып бактым:
Янмыйм-көймим.
Сабыр гына йөрим,
Сүзне үлчәп сөйлим,
Кычкырып та көлмим,
Бар нәрсәне
Гел уңайга көйлим,
Моң-зарларның
Ни икәнен белмим...

Берзаманны күрәм:
Күңел утым сүнгән,
Учак урынында
Салкын урын калган
Күмер белән көлдән...

Аның каравы
Мин тынычлык таптым!
Тик...
Үземне югалттым...

Соң булганчы, диеп,
Йөгерә-йөгерә,
Тынгысызлыгыма –
Үз-үземә кайттым!

## ЯЗМЫШ СИНЕ ҖИРДӘН АЕРМАСЫН...

Гөл битенә кунган чыклар төсле,
Керфегеңә яшьләр эленгән.
Сөйгән ярың тартып алдылармы?
Аердылар мәллә иленнән?

Нинди кайгы төште башларыңа?
Нигә болай моңсу карыйсың?
Сәхрәләргә чык син, болыннарга...
Чәчләреңне җилләр тарасын.

Син Кояшка эндәш, чәчәкләргә –
Җир җылысын кабат тоярсың.
Кояш күргән гөл чәчкәсе төсле,
Күңелеңдә өмет уянсын.

Һәммәсе дә булыр үз урынында,
Авырлыклар төшәр иңеңнән.
Язмыш сине җирдән аермасын,
Аермасын гына иленнән!

# ЯР АСТЫНДА КОЯШ БАЕДЫ*

*(Җыр)*

Башын иеп тып-тын калды әнә,
Сагышланды гөлләр, кайгырды:
Җир читенә төшеп югалгандай,
Яр астында кояш баеды.

Уйга чумып басып торам мин дә,
Шәфәкъләрдән күзем аермый:
Тагын бер көн төшеп югалды бит –
Яр астында кояш баеды.

Көннәр көнне куа ашыктырып:
Яшәү гаме, тормыш ваемы...
Киләчәктән нәрсә өмет итәм? –
Яр астында кояш баеды.

Чык күзендә тагын җемелдәргә,
Юарга дип җирдән кайгыны,
Ялт иттереп иртүк чыгарга дип,
Яр астында кояш баеды...

* Наил Гарипов көе.

# МӨЛДЕРӘМӘ ТУЛЫ КҮҢЕЛЕМ

Боз сәхрәсе кебек бушап калсам,
Мин бөтенләй кеше түгелмен.
Гел чайкалып, дәрья кебек ташып,
Дулкынланып торсын күңелем.

Калсын, әйдә, калсын шикләнүләр,
Уйлар диңгезенә күмелеп.
Ул диңгездән, энҗе тапкан кебек,
Хаклык эзләп табар күңелем.

Гел шатлыктан җырлап торсын, димим,
Кайгысын да тигез күрермен.
Кайгы килсә, горур булып калсын,
Сыгылмасын иде күңелем.

Тынмас, ахры, бер кузгалган дулкын,
Аны тыю мөмкин түгелдер.
Тик чайкалсын дулкын-дулкын булып
Мөлдерәмә тулы күңелем.

# ЙӨГЕРӘ-ЙӨГЕРӘ БАРАМ...

*Милләттәшләремә*

Елга булып күңел ташыганда,
Мөлдерәмә булып тулганда,
Йөгерә-йөгерә барам каршыгызга,
Сезсез яши алмыйм, туганнар.

Менә явам, менә явам диеп,
Баш очымда болыт торганда,
Йөгерә-йөгерә барам каршыгызга,
Сез – Кояшым минем, туганнар.

Бураннарда калып адашканда,
Салкыннарда калып туңганда,
Йөгерә-йөгерә барам каршыгызга,
Җылытыгыз мине, туганнар.

Бер афәт тә Җирдә яный алмас,
Барыбыз да бергә булганда.
Йөгерә-йөгерә барам каршыгызга,
Чит итмәгез мине, туганнар!

* * *

*Л-гә*

Күзләреңне каплап алса
Сагыш-хәсрәт томаны,
Кояш булып була микән,
Күләч булып буламы?

Күзләреңне томаласа
Өметсезлек томаны,
Кояш булып булмыйдыр ул,
Болыт булып буладыр.

Баш очында канат җәйсә
Ике башлы каракош,
Бетерәм бит башыңны, дип
Яный калса кара көч;

Менә хәзер төшеп китәм,
Инде беттем, дигәндә,
Якты дөнья йөзе белән
Саубуллашып йөргәндә,

Упкыннардан тартып ала
Мине бәхет кошларым –
Томаннарны таратучы
Кояшка тиң дусларым.

* * *

Дөньяга көлеп-елмаеп
Яшәргә килгән идем.
Җиргә мин бәхет гөлләре
Чәчәргә килгән идем.

Бар да бөтен, тулы кебек,
Бар күк болай бары да...
«Бәхетең кайда?» – диеп сорый
Күктә моңлы Ай гына.

Кайларда гына абындым,
Упкыннарга төшәрлек?
Якты Кояш кирәк миңа –
Гөлләр булып үсәрлек!

Туган туфрак кирәк миңа,
Тургайлар җыры кирәк!
Ятып кочаклап еларга
Арышлар кыры кирәк!..

## ТЫЙМАГЫЗ ЙӨРӘКНЕ!

Тыймагыз, тыйма йөрәкне,
Дуласын, янсын, әйдә!
Акылдан язсын, тилерсен,
Бер янып калсын, әйдә!

Тыймагыз, тыйма йөрәкне,
Тоткын кош түгел ич ул.
Җырлыйм дип атлыгып торган
Ярсулы күңел ич ул!

Язын ярга сыймый аккан
Елгадай ташый ич ул.
Тыймагыз, тыйма йөрәкне,
Давылга гашыйк ич ул!

* * *

Назга, иркәләүгә туймас
Бу күңелгә
Кешеләрнең җылы карашы
Тулсын иде
Кояш нуры булып.
Яңа көннәр тынгысызлыгы,
Тып-тын яткан
Дулкыннарны уятып,
Керсен иде җанга ургылып.
Сандугачлар җыры
Тулсын иде йөрәгемә
Җанга ятышлы бер
Моң булып.
Туган җирем яме
Балкып торсын иде
Күңелемдә
Таңнар булып кына
Сызылып.
Дөньям иркен,
Күңелем даладай киң.
Барлык ямен Җирнең
Үземә җыям,
Барлык төсне җыйган
Су тамчысы төсле.
Һәммәсе дә Җиргә яңадан
Җылы булып,
Җыр булып иңсен өчен.

# КҮБӘЛӘК

Язгы иртә. Кояш балкый,
Нурлар таган атына.
Тәрәзәбез каршысында
Бер күбәләк талпына.

Оча, китә, тагын килә,
Күбәләк соң ни аңлый?!
Пыяла да вата алмый,
Бүлмәгә дә кералмый.

Ә аннары... нишләсен ул
Сырхаулар арасында?
Сизмичә дә кулым сузам
Сап-сары канатына.

Мин дә тәрәзә каршында –
Шул күбәләк хәлендә.
Ә шулай да мин бәхетле
Гомернең бу мәлендә.

Яз килә, дөнья уяна.
Ак өмет – җаным тулы.
Яз килә Кояш төсендә –
Сары күбәләк булып.

# ГАҖӘП ТҮГЕЛ

Мин елмая идем бар дөньяга,
Мин елмая идем гөлләргә.
Язмыш әллә җәза бирде микән
Кайгы килгәндә дә көлгәнгә?

Хәзер инде шатлык килгәндә дә
Моңлы булып туа җырларым.
Сизеп торам еллар узган саен
Нечкәргәнен күңлем кыллары.

Нечкәрсә дә гаҗәп түгел инде,
Өзелер дә әле беркөнне,
Көйли-көйли җирдә иң аһәңле,
Иң сагышлы, моңлы бер көйне.

Беләм ич мин җирдә сагышларның
Шатлыклардан күбрәк булганын.
Минем күңел, ахры, сыйдыргандыр
Зар-моңнарын бөтен дөньяның...

Миңа язган бугай тибрәтергә
Иң-иң нечкә күңел кылларын.
Шуңа, бәлки, тормыш талларына
Моңлы былбыл булып кунганмын.

* * *

Биш пар күзне йокы ала алмый,
Ярсып-ярсып тибә биш йөрәк.
Гомер буе йокы күрмим әле
Дигән сыман, көмеш ай көлә.

Тәрәзәдән карый салкын гына,
Палатага безнең күз сала.
Назы да юк, моңы, җылысы да,
Ничек яши соң ул дөньяда?

Үзе болай матур матурын да,
Нигә салкын көмеш нурлары?
Читтән алган нурлар белән генә
Булмыйдыр шул җылытып дөньяны...

## НӘРСӘ ӘЙТИМ?

Үтә еллар, сагыш-моңнар
Сарылыша иңнәргә;
Сәхифәләре гомернең
Оча бара җилләргә.

Оча-китә, уза-туза, –
Җыеп алырмын димә...
Җилнең бар эше – туздыру,
Нәрсә әйтәсең җилгә!

Җаным тулы әрнү белән,
Күзем тулы сагыш-моң.
Ул моң юлга түгелеп кала –
Киләчәккә барышым.

* * *

Карурманда килә югаласым,
Адашасым килә юлларда.
Заман шавын онытып тик беразга,
Урман шавын телим тыңларга.

Карурманда килә югаласым,
Тик бер генә көнгә булса да.
Төрле яклап уйлар чага мине, –
Шөпшә кебек уйлар – усаллар.

Карурманда килә югаласым,
Күбәләкләр булып уйныйсым.
Бәлки, урман әйтеп бирер иде:
Ник күңелләр болай уйлы соң?

Карурманда килә югаласым,
Кошларына кушылып җырлыйсым.
Әче яшьләремнән арынганчы
Үксеп-үксеп килә җылыйсым.

Карурманда килә югаласым,
Агачларын кочып йөрисем.
Диңгезләргә төшкән тамчы кебек,
Яшел дәрьясында эрисем...

Карурманда килә югаласым...

* * *

Нигә тыныч була алмый минем күңел?
Кемнәр салган күңелемә бу давылны?
Аргамактай ярсу йөрәк бабамнармы?
Әллә җаннан газиз күргән авылыммы?

Өзелеп төшкән яфракка да күңел әрни,
Чәчәкләрдә тузан күрсәм, эчем поша.
Сабыйларның елаганын тыңлый алмыйм,
Үзем дә бит сабый булган инде юкса...

Әле һаман сабыйлыктан чыгып булмый,
Һаман елыйм сабыйларча үксеп-үксеп.
Ә сөенсәм, күзләремнән нур түгелә,
Нигә шулай алгысынам, Алла белсен!

Актарыла, бөтерелә – әйтерсең лә
Боз кузгалган язгы елга минем күңел.
Кемнәр салган күңелемә бу давылны?
Ник ярсый ул, нигә сабыр, тыныч түгел?!

## ДИҢГЕЗ ДИМӘ...

Диңгез димә минем күңелемне,
Дулап аргач, диңгез тына ул.
Тормыш мине һәрчак бөтереп тота,
Сынау арты җибәреп сынавын.

Ә сыналган чакта бертуктамый,
Тынып калып була димени?!
Нәрсә соң ул диңгез минем алда? –
Диңгез димә минем күңелне...

## КҮРӘСЕҢМЕ?

Гомер буе бәргәләнмәс өчен
Читлектәге киек кош кебек,
Алда торган кара упкыннарга
Төшеп китмәс өчен ишелеп.

Ни кылырсың икән, Кеше генәм,
Ни кылырсың икән, кыз бала?
Күрәсеңме, инде көн авыша,
Күрәсеңме, Кояш кызара?!

* * *

Сөенсеннәр, әйдә,
кайберәүләр, –
Тиле, диеп, әйдә,
көлсеннәр...
Ләкин алар
шуны белсеннәр:
Уй-хисләрне,
хәсрәт-борчуымны
Кешеләрдән
мәңге яшермәм.
Күңелләре тулгач,
күкне дер селкетеп,
Бушаналар шулай
яшеннәр...

## ХӘТЕР

Күңел үзе яхшылыкта,
Тик ялгышлар булып тора.
Хәтер – явыз: оныттырмый,
Кәефне гел кырып тора.
Ялгышларны саный-саный,
Яңаларын кылып торам.
Хәтер – явыз: оныттырмый,
Кәефне гел кырып тора.
«Акыллы бул икенче!» – дип,
Колакны гел борып тора.

* * *

Акбүз атым, әй, ярсыган:
Ак күбеккә батып-батып
Оча гына – атылган ук,
Яшь үләннәр кала ятып.

Оча гына акбүз атым,
Әллә җирдән, әллә күктән.
Ак күбеккә баткан килеш
Кая барып егылыр икән?!

* * *

Дөнья мәшәкатьләреннән арып,
Тәмам хәлдән таеп,
Барына кул селтәп,
Ялгызлык диңгезенә баттым...
Иң зур хәсрәтемне
Шунда таптым.

* * *

Бер кителсә, дөнья гел кителә,
Бер сүтелсә, йомгак сүтелә.
Кире ураулары, ай-һай, кыен,
Сүтелмә син, йомгак, сүтелмә!

Бер кителсә, дөнья гел кителә,
Гел кирегә китә эшләрең.
Мондый сулпән түгел идең бит син,
Әйтче, йөрәк, әйтче, нишләдең?

Бер сүтелсә, йомгак гел сүтелә,
Гел сүтелеп бетсә, нишләрмен?
Кире урау өчен вакыт җитмәс,
Сүтелмәскә көч бир, и Тәңрем!

## ЭНДӘШМИМ

Күңелемнең нечкә чагы иде,
Башым куйдым искән җилләргә.
Нәрсә мәҗбүр иткән ул җилләрне
Бар дөньяга зарым сибәргә?!

Аңлаганы, бәлки, аңлагандыр,
Усаллары бары көлгәндер...
Үзем генә белдем йөрәгемне
Әрнү уты ничек телгәнен.

Әле уңнан, әле сулдан искән
Җилләр белән хәзер серләшмим.
Гөлләр кебек сыгылып төшкәндә дә
Тешем кысып түзәм, эндәшмим.

* * *

Күзләр килде күңел кырларыма,
Кырау сукты чәчкә-гөлләрне.
Ашыгып килер диеп кем уйлаган
Көтелмәгән кара күзләрне?

Ни җылысы хәзер, ни яктысы –
Кояш инде болыт артында.
Коя гына яңгыр – әй, шәфкатьсез! –
Соры дивар минем каршымда.

Уч төбедәй бер яктылык сизсәм,
«Уф», – дип әйтер идем, котылып.
Кояшның бер җылы нурын күрсәм,
Күккә менәр идем тотынып.

* * *

Аңлый алыр микән мине
Бу елга камышлары?
Аларның үз хәсрәте ич,
Үз кайгы-сагышлары...

Мин, гомерем үтә, димен,
Алар, көз җитә, диләр;
Мин, чәчемә кырау төште,
Алар, су китә, диләр.

Аңлый алды бугай мине
Бу елга камышлары.
Зарыбызны күмеп китте
Аккан су тавышлары...

## ХАЛӘТ

Кайда мин? –
Берни белмим,
Берни аңламыйм –
Әллә Җирдә,
Әллә Айда мин.
Тирә-ягым
Ап-ак яктылык,
Бөтен җирдә –
Көмеш моңсулык.
Берни белмим,
Берни аңламыйм –
Әллә Җирдә,
Әллә Айда мин...

## И ЙӨРӘГЕМ!..

Алда кара, шомлы көннәр торганда да,
Ап-ак өмет, якты көннәр ышандырдың.
Кайчакларны ул өметләр акланмады,
Тик барыбер сиңа гына ышандым мин.

* * *

Су болгану гаҗәпмени,
Заманалар болгансын да...
Үз-үзеңне табу кыен
Мондый мәхшәр арасында.

Дөрләп янган тәмуг бу җир,
Янасын да, каласын да
Белми Кеше, бәргәләнә
Меңләгән ут арасында...

## АЧУЛАНМА, ДИҢГЕЗ!

Тәгәрәтеп дулкыннарың,
Ярга таба ишеләсең.
Бик тәкәббер холыклысың,
Масаясың көчеңә син.

Мәһабәтсең, дәһшәтлесең,
Көч күп синдә, анысын беләм.
Давылларда шашынасың
Коточкыч бер ярсу белән.

Ачуланма, мин аңламыйм
Мәгънәсез бу ярсынуны.
Нәрсә соң бу: шушы гүзәл,
Киң дөньяны тарсынумы?

Күңел рәнҗи тик торганнан
Өермә күк дулавыңа.
Әйтче миңа: нәрсә җитми
Синең шашкын суларыңа?

Бик сагындым җайлап кына,
Җырлап аккан Иделемне.
Аңлый алмыйм сине, диңгез,
Ачуланма, китәм инде!

## ЙӨГЕРЕП ЧЫКТЫМ УРАМНАРГА

Йөгереп чыктым урамнарга, –
Таңнар аткан чак иде:
Дөнья әле алсу иде,
Үзәннәргә зәңгәр ефәк
Томан яткан чак иде.

Йөгереп чыктым урамнарга, –
Кояш батар чак җиткән:
Җиргә моңсу эңгер төшкән,
Бер дә үтмәс төсле иде,
Бу гомер кайчан үткән?!

## ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ

Юлга чыгар алдыннан
ак көчек күрсәң, юлың
уң булыр...

*Әни сүзе*

Яңа елның иң беренче көне...
Ап-ак көчек күрдем иң элек.
Әнкәй сүзен искә төшердем дә,
Уйлап куйдым эчтән сөенеп:

«Бу ел, бәлки, мәрхәмәтле булыр,
Гел генәме газап чигәргә?!
Узгандагы әрнү, бәлки, калыр
Искә алып кына сөйләргә?!»

Ак көчегем китте ап-ак юлдан,
Коерыгын болгап, сәламләп:
Әйтерсең лә ап-ак кышкы юлдан
Ак өметем бара тәгәрәп...

# РӘХМӘТ!

Җаным сызлаган,
Мием кайнаган чакларда
Миңа ярдәм биргән
Суга рәхмәт!
Ул мине
Шартлаудан коткарды.

Күңелем салкынаеп,
Туңам дигәндә,
Мине бозланудан коткаручы
Утка рәхмәт!

Хәлсезләнеп,
Алҗып,
Инде авам дигәндә,
Мине тотып калган
Имәннәргә рәхмәт!

Көчсезлектән тәмам гаҗиз булып,
Яшәүләрдән туя башлаганда,
Канатына утыртып китәргә
Әзер торган
Каурый болытларга рәхмәт!

Авыр – дөньяларда яшәүләре...
Ә шулай да
Рәхәт!..

## АРТКАН САЕН...

Кирәк була калса әгәр,
Диңгез кебек дулармын;
Кирәк икән, ташка ятып,
Бер туйганчы елармын.

Кирәк булса, елгаларын
Кирегә дә борырмын;
Кирәк икән, давылларда
Кыяташтай торырмын.

Сәерсенмәгез, көрсәгез,
Нигә, дип, шулай ярсый?
Миндә – давылларның шавы,
Кайнарлыгы Кояшның.

Миндә – Җиремнең ныклыгы,
Уйламагыз: «Кыз бала...»
Авырлыклар арткан саен,
Мин ныгый гына барам.

* * *

Кеше башы саен хәсрәт,
Адым саен кайгы.
Күрмәс хәлгә килә кеше
Кояш белән Айны.

«Нишләп болай?» дигән сорау
Тынгы бирми миңа.
Нигә кеше күмелгән соң
Сагыш белән моңга?

Тынгы бирмәс бу сорауны
Кемгә биреп багыйм?
Әллә нинди өмет белән
Йолдызларга карыйм...

* * *

Күңелемнең кылдан нечкә чагы,
Кагылмагыз аңа, дусларым.
Күзләремдә яшь бөртеге күреп
Сөенмәсен әле дошманым.

Минем җанга үтеп кералмаган
Аңлый алмас минем хәлләрне.
Аңлый алмас якты җир йөзенә
Гашыйк булып йөргән мәлләрне.

Һәр тамчыда кояш күрәм бүген,
Ә кешеләр нинди сөйкемле!
Мин үзем дә җиргә яңа туган
Бер гөнаһсыз сабый шикелле...

Күңелемнең бик нечкәргән чагы,
Кагылмагыз аңа, дусларым.
Күзләремдә яшь бөртеге күреп
Сөенмәсен әле дошманым...

## Ә ЯР ТЫНЫЧ...

Авыр сулый, ярсый-дулый диңгез,
Дулкыннары – кургаш, тау чаклы.
Кая киткән яшькелт матурлыгы,
Йөзен бозган нигә шулчаклы?

Авыр сүзләр ишеткәнме әллә,
Әллә артык горур микән ул?
Әллә болай үзе холыксызмы?
Берәр вакыт тынар микән ул?

Күзем алмый ярда басып торам,
Тау-дулкыннар мине сихерли...
Ә яр тыныч, сабыр гына көтә,
Үтәр-үтәр дигән шикелле...

## КИЕРЕП АЧ, ӘЙДӘ, ТӘРӘЗЛӘРНЕ...

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне, –
Бөркелеп лә керсен саф һава.
Күкрәк тутырып та суламагач,
Җирдә безгә тагын ни кала?

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне, –
Арыныйк бер, әйдә, тузаннан.
Сусаганбыз сафлык, чисталыкка, –
Безнең җаннар шуңа кузгалган!

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне, –
Бер елмаеп кара Кояшка!
Болыт чыкты, диеп, яшәүләрдән
Туялар димени бу яшьтә?!

Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне, –
Ургылыплар керсен саф һава!
Күкрәк тутырып та суламагач,
Бу дөньяда тагын ни кала?!

* * *

Дулкынлана диңгез, күбекләнеп,
Котырына, ярсый, шашына.
Рәхәтләнеп йөзеп булмас, ахры,
Иркәләнеп Кояш астында...

Дулкынлана диңгез, котырына, –
Акчарлаклар кунган өстенә.
Акчарлактан киммени соң Кеше, –
Ташланамын дулкын эченә...

## ӘДРӘН ДИҢГЕЗ!

Әдрән диңгез, шаулы диңгез,
Ай, шаулы диңгез...

Әдрән диңгез, назлы диңгез! –
Суларыңны сагындым.
Суың тарта, туган ягым
Тарткан кебек җанымны.

Әдрән диңгез, зәңгәр диңгез!
Кайдан мондый зәңгәрлек?
Каян таптың илаһи көч
Йөрәгемне бәйләрлек?

Әдрән диңгез, иркә диңгез! –
Син нигә шундый тозлы?
Хәтерлимсең күз яшьләре
Суыңа тамган кызны?

Әдрән диңгез, моңлы диңгез!
Саф суыңны сагындым.
Тартасың бит, туган ягым
Тарткан кебек җанымны...

## МИН, КЕШЕЛӘР, СЕЗГӘ ҮПКӘЛӘМИМ...

Туңган-өшегәндә, җылы эзләп,
Мин атылдым сезнең кочакка.
Ут булдыгыз, рәхмәт, җылыттыгыз,
Боз да булдыгыз шул кайчакта.

Җиргә килгәч, үз урынын эзли:
Юк, яшисе килми кимсенеп;
Үз сукмагын эзли горур Кеше,
Хакыйкатьне эзли җилкенеп.

Юлга бергә чыккан идек тә бит,
Аерылып кемдер атлады.
«Минеке дөрес!» – диеп күкрәк сукты, –
Һәркем үзенекен яклады.

Барыбыз да җирдән чыккан затлар,
Әкрен-әкрен җиргә кайтырбыз.
Шул мәңгелек йортка китәр икән
Тыныч күңел белән кайсыбыз?

Мин, кешеләр, сезгә үпкәләмим:
Адашканнар Җирдә азмы соң?
Дөреслекне эзләп, еллар аша
Ал таңнарга китеп барышым...

* * *

Каян гына алыйм,
Каян алыйм җегәр?
Тормыш кай урында
Аяк чалып егар?
Эчке тавыш миңа
Сак булырга куша;
Һәр адымда гадел,
Хак булырга куша;
Шул чагында, ди ул,
Кая борылсаң да,
Җаның чиста калыр,
Кайда егылсаң да!

## ХЫЯЛ, НИГӘ АЛДАДЫҢ?

Яшәү – тоташ җыр гына, дип,
Хыял, нигә алдадың?
Сандугачлы бу дөньяда
Козгын да бар, аңладым.

Бар кеше дә тигез, диеп,
Хыял, нигә алдадың?
Бар яхшылар, бар яманнар:
Хәзер инде аңладым.

Яшәү – бәхет кенә, диеп,
Хыял, нигә алдадың?
Адым саен бәхет көтеп
Тормый икән, аңладым.

Барысы да ап-ачык, дип,
Хыял, нигә алдадың?
Мин берни дә белмәгәнмен.
Хәзер генә аңладым.

## УТ

Сиңа түгел, үземә дә
Ышанмыйм, диде берәү.
Синең белән утны-суны
Кичалмыйм, диде берәү...

Көннәремне якты иткән
Кояш нуры өзелде.
Кем гаепле икән моңа?
Әллә инде үземме?

Күңел сүрелүеме бу?
Гайбәтчеләр эшеме?
Ышанычы-уты сүнсә,
Ни яшәтә кешене?

И көйдерә рәхимсез ут –
Көйдерә йөрәк турын...
Ничек итеп ялгыйм икән
Өзелгән кояш нурын?!

## ТЕЛӘК

Килә
Авыр минутларда
Җилләр булып елыйсым,
Ташкын булып агасым,
Тамчы булып тамасым,
Утлар булып янасым...
Юк!
Җилләр дулаганда да,
Язмыш кызганмый кыйнаганда да,
Кеше булып каласым килә...

## ЯШЕН БУЛЫП

Нәрсә әрнетә йөрәкне? –
Тибә гел сулык-сулык.
Мөлдерәмә күзләр төсле,
Күңелләр тора тулып.

Чалт аяздай иде күгем, –
Каян чыкты бу болыт?
Бар күкне капламак булып
Бара хәзер куерып.

Нәрсә кирәк ул болытка?
Нәрсә калган күгемдә?
Таратыйм әле мин аны,
Яшен булып телим дә!

* * *

Болганчык су төсле
соры көннәр
Тәмам үзәккә үтте.
Түземлелек
соңгы чиккә җитте.
Инде бар да бетте,
аяз көннәр
Кире кайтмаска китте,
дип йөргәндә,
Кояш нуры
кереп тулды бүлмәмә!

# КИТМИМ ӘЛЕ ЯШЬЛЕГЕМНӘН*

*(Җыр)*

Бер-бер артлы еллар уза,
Көмеш өстәп чәчләремә.
Ә шулай да мин ышанам
Яшен булып яшьнәремә.

К у ш ы м т а:

Без бит җиргә якты, җылы
Ямь өстәргә яратылган.
Китмим әле яшьлегемнән –
Яз гөлләре арасыннан.

Уйлар әле шактый зурдан –
Язлар алып килү күздә.
Алда әле ак өметләр,
Йөрәк һаман унсигездә.

К у ш ы м т а.

Якты кояш, ал гөлләргә
Килә һаман сөенәсе,
Елый-көлә, яна-көя
Яратасы-сөеләсе.

К у ш ы м т а.

---

* Луиза Батыр-Болгари көе.

## КИТМӘ, КОЯШ!*

*(Җыр)*

Китмә, Кояш, китмә, Кояш,
Качма болыт арасына!
Синең җылың, яктың кирәк
Былбыл-кошның баласына.

Синнән башка нинди кызык,
Нинди ямьнәр калсын Җирдә?!
Былбыл-кошның баласына
Ник Кояшсыз тилмерергә?!

Сандугач бит килә Җиргә
Яшәү көен җырлар өчен.
Гомерен дә бирер кеше
Аның көен тыңлар өчен...

Китмә, Кояш, китмә, Кояш,
Качма болыт арасына.
Синең җылың, яктың кирәк
Былбыл-кошның баласына!

## ШАГЫЙРЬ ГОМЕРЕ

Шагыйрьләрнең күңеле нечкә була,
Шагыйрь күңеле – сабый күңеле.
Шагыйрьләрнең гомере кыска була,
Шагыйрь гомере – чәчәк гомере.

Шагыйрьләрнең гомере кыска була,
Бер атылган йолдыз гомере.
Шагыйрьләрнең гомере озын була,
Шигырьләре җиңсә үлемне.

---

* Рәшит Кәлимуллин көе.

* * *

Белмим бугай сине...
Юк, син миңа таныш:
Йөрәгеңдә – җырлар,
Күзләреңдә – сагыш.

Елау-көлүләрең,
Күз карашың бүтән.
Белмим бугай сине...
Юк, юк, беләм күптән.

Атлавыңнан түгел,
Җырлавыңнан таныйм.
Якты сагыш тулы
Җырларыңнан таныйм.

Җиңел сулап куям,
Күзләреңә карыйм:
Син һаман да үзең, –
Әйе, сине таныйм!

Җырлар тулы еллар,
Юллар алга дәшә...
Югалтышмыйк бүтән –
Атлыйк гел янәшә!

* * *

Баш очымда болыт куера –
Кысылыплар китә йөрәкләр:
Тик чылатып кына үтәрме,
Кояр микән әллә чиләкләп?..

## Җыр булып калдың...

*Сәҗидә Сөләйманова истәлегенә*

Кояшның бер нуры җитә
Сискәндерер өчен гөлне.
Чайкалдырдың, сискәндердең
Мөлдерәмә күңелемне.
Уйларымны сискәндереп,
Моң агылды, моң түгелде...

Җитә бер җил исүе дә
Кузгатырга дулкыннарны.
Күңелләрне кузгаттың да,
Ник бик иртә китеп бардың?
Уйга салдың, моңга салдың,
Йөрәктә җыр булып калдың.

## Аккош моңы

*Башкорт шагыйрәләре*
*Дилә белән Халисәгә*

Ташны ярып үсә яшел үлән,
Болытлардан үтә Кояш нуры...
Ниләр белән тыңлим үзегезне?!
Ниләр белән тыңлим сезнең җырны?!

Яшен уты, ләйсән тамчылары –
Бар да бар ич сезнең җырыгызда.
Югалдыгыз, җанга җылы җилпеп,
Аккош канатлары булдыгыз да.

Ярып үтте җанны урталайга
Аккош иңрәведәй сезнең тавыш...
Йөрәкләрне пәрә-пәрә телә –
Сезнең моңнар таныш миңа, таныш!

Аккош иңрәведәй сезнең тавыш...

## АК БУРАНЫМ – АК КАНАТЫМ

Бик сагындым авылымны,
Бурап яуган карларымны;
Ак көртләрне, ак өйләрне,
Ак юрганлы кырларымны...

Ак бураным – акбүз атым,
Утыртып ак канатыңа,
Илтеп куйчы җилтерәтеп
Ак авылыма – җанашыма.

Илтеп куйчы, ак бураным,
Авылым бит янда гына...
Күз яшедәй чиста карлар,
Ап-ак карлар анда гына.

Шундый сусадым аклыкка,
Ак карларга гашыйк ич мин.
Гомерем буе шул аклыкны
Сагыныплар яшим ич мин...

Ак бураным – ак канатым...

## МИНЕМ ДӨНЬЯМ

Мин бүген сәер дөньяда:
Тимәгез миңа бүген.
Башымда уйлар урала,
Бертоташ – җирем, күгем.

Мин бүген фани дөньядан
Өскәрәк аштым бугай:
Мин бүген тилердем бугай,
Мин бүген шаштым бугай!

Сәер дөньям шундый җиңел,
Фәрештә канатыдай;
Мин бәхетле әсир бүген
Хисләрем арасында.

Күңелемнең оҗмахы бу:
Кояш та гөлләр генә;
Монда Ләйлә, монда Мәҗнүн
Мәхәббәт мөнбәрендә.

Үпкә дә юк, ачу да юк, –
Шундый гүзәл дөнья бу!
Һәркем үзе булып кала,
Монда беркем «уйнамый».

Алга-артка карану юк,
Беркем «сатмый» беркемне.
Син кош кебек иреклесең –
Бар җирдә хөрлек, киңлек.

«Ак»ны «кара» диюче юк,
«Ак» димиләр «кара»ны;
Монда «тәлинкә тотарга»,
Ялганларга ярамый.

Минем иң изге дөньям бу –
Җырларымның дөньясы!
Бу – миңа канатлар куйган
Хыялымның дөньясы!

# АК РОЗАЛАР

*Хәсән ага Туфан истәлегенә*

Язмыш сине бездән алып китте
Үлемсезлек иле ягына...
Ак розалар, ак болытлар төсле,
Агыла да һаман, агыла...

Халкым, диден, өзелеп җырларыңда,
Аның өчен җырлап туймадың.
Судан алып утка салды язмыш,
Син җырлаудан барыбер тынмадың...

Җырлар туа, еллар үтә торды,
Ашыга ла еллар, ашыга...
Чал чәчләрең җилдә җилфердәтеп
Җырлап кайттың халкың каршына.

Син халкыңа ак розалар бирдең,
Тамыр җәйсен, диеп, күңелендә...
Юк, син ялгыз түгел идең, түгел:
Өең дә бар иде, илең дә.

...Ак розалар, ак болытлар төсле,
Агыла да һаман, агыла...
Язмыш сине бездән алып китте
Үлемсезлек иле ягына...

Ак розалар һаман агыла...

*11 июнь, 1981 ел*

# «ХУШЛАШМЫЙ ДА КИТӘМ...»

*Яраткан шагыйребез Фәннур Сафинның якты истәлегенә*

Бигрәк усал язмыш дигәннәре –
Шагыйрь дип тә тормый, яшь дип тә.
Китеп бара Фәннур... Китеп бара...
Картлыгында түгел, яшьлектә.

Китеп бара Шагыйрь... Юл чатында
Кулын изи сыман елмаеп:
«Сез борчулы?.. Үтәр, кайгырмагыз,
Мәшәкате фани дөньяның.

Әҗәл генә үтми – һәр заманда
Котылып калган аннан кемнәр соң?
Төрле вакыт йөри – тик шунысы –
Кемгә иртә килә, кемгә соң.

Сезнең язмыш бүтәнчәрәк булыр,
Минем язмыш шулай очланды.
Чуалды да тормыш йомгаклары,
Таба алмадым шул очларын...

Хушлашмый да китеп барам менә:
Рәнҗемәгез, минем гаеп юк.
Дөнья дәшми хәзер, күкләр дәшә –
Күккә очам ап-ак кош булып.

Ялгыз аккош сыман китеп барам,
Ал таңнарга җитеп булмады.
Китеп барам ялгыз аккош төсле,
Очар канат итеп кулларым...

Юк, сызмагыз мине күңелегездән –
Мин китмәмен, ахры, китмәмен...
Йөрәкләрдә сезнең калырмын мин
Моңлы җыры булып чишмәнең».

*5 гыйнвар, 1993 ел*

* * *

Югалып калган чакларда
Усал язмыш алдында,
Гел өмет юата безне,
Шул өметләр алдый да...

## БОЛЫТ

Болыт канаты тия дә
Кояш нурын чылата.
Шул бер кара болыт инде –
Кояшны шул елата...

## КӨНЬЯККА КИТКӘНДӘ

Нигә болай бик ямансу әле?
Күңелләрдә – сагыш...
Туган якның моңсу күзен ташлап,
Җәйгә китеп барыш...

* * *

– Йөзең көләч, ә ник әле
Моңлы, – диләр, – күзләрең?
Кая гына яшерим соң
Күңелемнең күлләрен?

* * *

Дөнья читтән карап тора
Җанда дулкын кузгалганын...
Тынычланса дулкын үлә,
Тынма, җаным, тынма, җаным!

* * *

Бер дулкыны, димим, зур диңгезнең –
Бер тамчы мин, бары бер тамчы.
Шул тамчыга тулган кояш булып
Гомер буе балкып торсаңчы!..

## ӘГӘР...

Сулар булып, елга булып еллар ага...
Мәңгелеккә килмәгән бит бу дөньяга.
Нинди матур үтәр иде бу гомерләр,
Бар йөрәкләр берсен-берсе аңлаганда.

* * *

Син шомланма, тиктән сискәнешеп,
Керфекләрем яшькә чыланса.
Бу бит күңел бозларының эреп
Агулары гына лабаса...

* * *

Хыял бераз хәйләли дә,
Бераз гына алдалый да.
Тик нигәдер җиңелрәк
Яшәү Җирдә хыялыйга...

## АВЫЛЫМ УРАМЫ

Төшләремә кереп йөдәттең дә,
Сагыну хисләремне тыялмый,
Очар кошлар төсле канатланып,
Сиңа кайттым, авылым урамы.

Бала очырган кош оясы төсле, –
Миңа гына шулай тоеламы?
Нигә болай тынып калдың әле,
Гөрләп торган авылым урамы?

Бәбкә үләне үскән тар сукмактан
Зур юлларга мине чыгардың.
Ялантәпи йөрткән чирәмеңә
Рәхмәт укыйм, авылым урамы.

Күңел ярсый язгы ташу кебек, –
Сагынуларга түзеп буламы?!
Язлар белән бергә тагын сиңа
Кайттым әле, авылым урамы.

## БАЛАЧАК

Өн булдымы, әллә төш идеме
Боз өстенә яккан ул учак?
Боз өстенә яккан учак төсле
Агып кына китте балачак...

## АЛТЫН КОЯШ, ЗӘҢГӘР КЫҢГЫРАУ...*

*(Җыр)*

Яшел болын. Көмеш инешем.
Балачакка кайтып килешем.
Алтын кояш. Зәңгәр кыңгырау.
Балачакка илткән юл урау.

Яшел болын. Гөлләр тибрәлә
Әкрен генә искән җилдә дә.
Алтын кояш. Зәңгәр кыңгырау.
Балачакка юллар, һай, урау!

Кайда соң сез, яшел болыннар?
Җир җиләге пешкән урыннар?
Алтын кояш. Зәңгәр кыңгырау.
Балачакка илткән юл урау...

* * *

Тәрәзәмә чиртә язгы яңгыр,
Ниләр әйтмәк миңа буладыр?
Әйдә, яңгыр, моңлы күңелемне
Әрнет әле, әрнет, сызландыр...

Тәрәзәмә чиртә язгы яңгыр:
Туган авылымнан сәламме?
Шык-шык итә, нидер әйтмәк була –
Әнкәемнән көткән хәбәрме?

Тәрәзәмә чиртә язгы яңгыр,
Тамчылары тама күңелгә...
...Хыялымда, яңгыр суын ерып,
Авылыма таба йөгерәм...

---

* Чулпан Зиннәтуллина көе.

# ТУГАН ҖИРДӘ ҖАНЫМ ТЫНЫЧ

*(Җыр)*

Туган якта битләремнән
Назлап ефәк җилләр исә.
Кошлар минем өчен сайрый,
Гөлләр минем өчен үсә.

К у ш ы м т а:

Туган якның һавасы да
Тәнгә сихәт, җанга дәва.
Монда минем җаным тыныч –
Борчуымны җилләр ала.

Таллар – сердәш, чишмә – көйдәш,
Каеннарым – сеңелләрем.
Онытырлыкмы бер керфеге
Монда үскән сөмбелләрнең?

К у ш ы м т а.

Монда үскән ал гөлләрнең
Керфегеннән баллар тама.
Монда минем җаным тыныч –
Борчуымны җилләр ала.

## КАР ВАЛЬСЫ*

*(Җыр)*

Яфрак-яфрак кына,
Ап-ак, ап-ак кына
Карлар ява зәңгәр күкләрдән,
Тияр-тимәс кенә,
Кыяр-кыймас кына
Кар бөртеге үбә битләрдән.

Әй ашкына күңел –
Бәйрәм алды бүген,
Бөтен дөнья актан киенгән.
Күздә – йолдыз нуры,
Йөздә шатлык уйный,
Һәммәсе дә шундый сөенгән.

Зәңгәр бәрхет һава,
Ап-ак карлар ява, –
Ул карларда пакьлек-сафлык бар.
Юлларым да ап-ак,
Ул юлларда мине
Көтә кебек бары шатлыклар.

* Мәсхудә Шәмсетдинова көе.

* * *

Кояшның бер нуры булсам,
Елмаеп карар идем, –
Ник Кояш булалмадым?!

Яңгыр булсам, бер кинәнеп,
Кырларга явар идем, –
Ник ләйсән булалмадым?!

Кар бөртеге булсам, кышын
Кырларга ятар идем, –
Ник карлар булалмадым?!

Кыр казы булсам, елына
Бер очып кайтыр идем, –
Ник кырказ булалмадым?!

## ГОМЕР ИКЕ КИЛМИ

Таллар тора оеп,
Су агышын тыңлап;
Тыңлаулары рәхәт, –
Сулар ага чыңлап.

Таллар тора боек,
Үз көйләрен көйли:
«Сулар кире акмый,
Гомер ике килми...»

Гомер ике килми... –
Кемнәр аны белми?!
Җанга ваем инде:
«Ә үз көең нинди?»

Гомер ике килми...

## ӘНКӘЙ ҖАНЫ*

*(Җыр)*

Шәфәкъларны алсу нурга манып,
Моңсуланып көн дә кояш байый.
Тынгы бирми бер уй йөрәкләргә:
«Рәнҗемәде микән әнкәй җаны?»

Заман кызу, без үзебез әле
Заманнан да кызу, кайнар канлы.
Шул кызуга тиеп, кайчакларны
Рәнҗемәде микән әнкәй җаны?

Кеше итеп юлга чыгарганчы,
Мең бәладән мине йолып калдың.
Коткара күр тагын бер хәсрәттән:
Рәнҗи күрмә миңа, әнкәй, җаным!

## ХӘЕРЛЕ КӨН ТЕЛИМ

Таңнар саен хәерле көн телим,
Аяз күкләр телим җиремә.
Кояшлы көн телим бар кешегә
Һәм иминлек телим илемә.

Хәерле көн, димен һәр бөҗәккә,
Хәерле көн телим гөлләргә.
Сөйкемлелек телим яшь кызларга
Һәм сабырлык телим ирләргә.

---

* Чулпан Зиннәтуллина көе.

Юлчыларга хәерле юл телим,
Чәчәкләргә карап елмаям.
Һәрбер кеше якын кардәш сыман,
Үз балам күк тоела һәр бала...

Таңнар саен хәерле көн телим,
Аяз күкләр телим Җиремә.
Кояшлы көн телим бар кешегә
Һәм иминлек телим илемә!

## БӘБИ КҮТӘРГӘННӘР ӘНИЛӘР...*

*(Җыр)*

Ап-ак челтәрләргә күмеп кенә,
Мамык юрганнарга төреп кенә
Бәби күтәргәннәр әниләр.

Бәхет дәрьяларын гизеп кенә
Аккош киләмени йөзеп кенә –
Бәби күтәргәннәр әниләр.

Күзләрендә кояш нуры уйный,
Йөзләрендә чагыла горурлыгы –
Бәби күтәргәннәр әниләр.

Ак чәчәкләр кунган чәчләренә,
Җирдә кара хәвеф яшәвенә
Ышана алмый япь-яшь әниләр.

Бишек җыры киләчәккә китәр,
Кояш сүнмәс, яшәү дәвам итәр
Бәби күтәргәндә әниләр.

---

* Роза Мөхетдинова көе.

## ӘЙТ, ӘНИЕМ, ҖИЛЛӘРГӘ*

*(Җыр)*

Бу нинди көн булды соң бу? –
Кары тузгый, җиле әче...
Әни, җаным, мондый җилне
Илче итеп җибәрмәче!

Юллама син әче җилләр,
Шом салмасын йөрәгемә.
Сезнең яктан иссен монда
Бары назлы җилләр генә.

Туган якның җиле йомшак,
Алар сине тыңлар иде.
Күңелемдә купкан буран,
Җил-давыллар тынар иде...

Әйт, әнием, әче җилләр
Шом салмасын йөрәгемә.
Сезнең яктан иссен монда
Бары назлы җилләр генә!

## И ӘНИЕМ!..

Япь-яшь кенә
Юка иңнәремә
Авырлыклар төште,
Авырлыклар.
И бу йөрәкләрнең
Чуарлыгы!

---

* Чулпан Зиннәтуллина көе.

Каян гына алыйм
Сабырлыклар?
Сабырлыклар җитми,
Сабырлыклар!
И әнием!
Үзеңдәге чиксез түземлекнең
Бер өлешен
Миңа бирсәң иде.
Син бит юмарт,
Бик тә юмарт кеше,
Бүтән вакытлардагыча:
«Ал, ал, кызым,
Миңа калганы да җитә», –
Дисәң иде...
И әнием!..

* * *

Бертуктамый, армый-талмый,
Көне-төне җилләр исә.
Ябырыла давыл булып,
Гөлнең яфракларын кисә.

Тукта, бераз исми тор, дип
Әйтеп буламыни җилгә?
Башын игән – ни хәл итсен? –
Барысы да күнелендә.

Көннәр үтә, төннәр үтә...
Җәйләр үтә, көзләр җитә.
Вакыты җиткәч туктар, диеп,
Гөлләр һаман сабыр итә...

## УЛЫМ БАР БИТ МИНЕМ

Улым бар бит минем, куанычым,
Таянычым – алтын канатым.
Нур сипсен дип Җиргә, исемен дә
Айнур диеп куйдым, яратып.

Ай нуры да, ил нуры да булсын,
Күңелемнең сүнмәс нуры да.
Үзем китсәм, җирдә улым кала,
Җир язмышы – улым кулында.

...Улым бар бит минем, мактанычым,
Ил терәге – алтын канатым.
Мин бәхетле, җирем үз улына
Айнурым дип дәшсә яратып.

## УЛЛАРЫМА

Сез – тере мәшәкатьләрем,
Көенү-борчуларым.
Кайчак уйлатып куясыз
Уйларның моңсуларын.

Иң-иң дәү шатлыкларым сез,
Тормышым куанычы.
Көч-куәт бирүчеләрем,
Күңелем юанычы.

Гомеремнең язы бит сез,
Яшәвем яме – сездә.
Яз ямьлерәк булган саен,
Яктырак була көзләр.

## ЕЛАМА СИН, УЛЫМ!..

Тиктормас шаян колыным,
Җанымнан газиз оныгым,
Илнурым минем, күз нурым,
Күңелемнең моңлы бер кылы син,
Җанымнан түгелгән бер моңым.
Өметем син минем, куанычым,
Беркемдә юк синдәй гүзәл бала,
«Дәү әни!..» – дип, күзләремә карап,
Ни көтәсең миннән, балакаем,
Бердәнберем минем, ятратканым?
Беләм инде, беләм, сизәм, күрәм –
Җылы җитми адәм баласына.
Йөрәгемдә булган бар җылымны
Сиңа бирәм – күзем карасына.
Дөнья бит ул гел сынаудан тора,
Син бөркет бул, улым, йә бер кыя.
Рәнҗетәләр икән, кичерә бел,
Энҗе яшьләреңне җиргә койма.
Гел Кояшка гына карап яшә,
Уең йолдызларга кадәр күчсен.
Матурлык ул барыбер җиңми калмас,
Баскан эзләреңдә гөлләр үссен!..

## БЕРДӘНБЕРЕМ СИН МИНЕМ*

*(Бишек җыры)*

Алтыным ла син, диеп,
Ялкыным ла син, диеп,
Үстерәм бәбкәемне
Иркәләп-сөеп.
Улыкаем син минем,
Колынкаем син минем;
Юлыма нур сибүче
Аем син минем.
Бәлли-бәү, бәлли-бәү.

Син минем ышанычым,
Бердәнберем дигәнем;
Син – бөркетем, лачыным,
Илгә бүләгем.
Матур булып үсәрсең,
Батыр булып үсәрсең,
Ак өметем син минем,
Бәхетем гөле.
Бәлли-бәү, бәлли-бәү,
Бәлли-бәү, бәлли-бәү...

---

* Луиза Батыр-Болгари көе.

## УЯТМАГЫЗ ЮККА БАЛАЛАРНЫ!

Татлы йокылар йокладым
Сабый чакларда гына.

*Халык җыры*

И, сабыйлар йоклый тәмле итеп,
Яннарында сакта – аналары.
Бүленмәсен татлы йокылары,
Уятмагыз юкка балаларны!

Тыныч үтсен төне сабыйларның,
Тыныч тусын тагын яңалары...
Йокласыннар тәмле төшләр күреп,
Уятмагыз юкка балаларны!

Җаны барлар, сабыйларга тиеп,
Сискәндермәсеннәр аналарны.
Сабый чак ул – татлы бер төш кенә,
Уятмагыз юкка балаларны!

## ДӨНЬЯГА НИЛӘР БУЛГАН?

Дөньяганиләр булган:
Каплаган мәллә томан?
Күкләр ап-аяз иде бит,
Дөньяга ниләр булган?

Әллә йоклаганнар инде:
Гөлләр дә күзен йомган.
Шау чәчәктә иде бакчам:
Дөньяга ниләр булган?

...Күкләр әнә аязган да,
Таралган инде томан.
Кояшны бик азга гына
Болыт каплаган булган...

## ИҢ ЗУР ҖИҢҮ

Мәшәкатьле дөнья ваклыклары
Баштан ашып китә.
Үзе белән сөйрәп төшмәк була
Әллә кая – төпкә...

Бар көчеңә кайчак тырмашасың,
Өскә чыкмак булып.
Көчең бетсә, шундый ачу килә,
Күңел китә тулып...

Иң зур сөю – вак-төяге белән
Җирне сөюдер ул.
Үз-үзеңне, ваклыкларны җиңү –
Иң зур җиңүдер ул.

## КАЕН

Куллары күккә сузылган –
Корыган инде каен:
Утырмас инде яшәреп
Ул язлар килгән саен.

Бер яфрак юк ак кәүсәдә,
Тәнендә мең-мең яра,
Куандырмый алтын кояш,
Кошлар да кунмый аңа.

Нәрсә булган соң каенга,
Нигә корыган каен?
Күзләремне томан сара
Аңа караган саен.

* * *

Акыллылар нык күбәйде,
Хыялыйлар гына сирәк.
Җирне бизәп яшәр өчен
Бераз «сәер» булу кирәк.

## ТИЛМЕРТМӘГЕЗ ГӨЛЛӘРНЕ!

Сулар сибеп үстермәсәң,
Гөл кояшка үрләрме?
Сусыз калып сулмасыннар,
Тилмертмәгез гөлләрне!

Гөл чәчәге күләгәдә
Ялкын булып дөрләрме?
Гел кояшка карасыннар,
Тилмертмәгез гөлләрне!

## КИТМӘС ИДЕ...

Нигә болай моңлана,
Нигә җаны сызлана?
Еракта калган әнисен
Өзелеп сагына кыз бала.

Моңланмас иде, сагыну
Утында яна шул ул.
Китмәс иде дә яныннан,
Үзе дә ана шул ул...

## ДАВЫЛ КИЛӘ...

Булды, җитте, ди Табигать,
Тынып күп яшәдегез.
Курку иңсен җаныгызга,
Түгелсен яшьләрегез.

Чайкалсын күңел-дәрьягыз,
Уянсын уй дулкыны.
Күкрәсен күк, яшенләсен,
Ачылсын тау упкыны...

Күпме йокларга була соң,
Болай яшәүләр нигә?!
Бар нәрсәне актарам, дип,
Ишелеп давыл килә...

* * *

Җирне ямьләп торган гөлне
Давыл килеп изеп китә.
Һич булмаса, яфракларын
Берәм-берәм өзеп китә...

Үтә гомер, сизелми дә,
Сизелми дә үтә көннәр...
Гел көрәш тә гел бәрелеш –
Ничек түзә нәфис гөлләр?!

# ӘЙ ИЛАҺЫМ, ТАШЛАМАЧЫ...*

*(Җыр)*

Юк җирләрдән бар иткәнсең,
Игелекле булсын, диеп.
Бәндәләрнең күңеленә
Кояш булып тулсын, диеп.
Әй Илаһым, рәхмәт Сиңа!

Мин яратам бар җиһанны,
Җиреңне дә, күгеңне дә.
Мәхәббәтең орлыкларын
Мул сипкәнсең күңелемә.
Әй Илаһым, рәхмәт Сиңа!

Күз өстендә каш түгелмен –
Авыр чаклар шактый булды.
Адашмаска, юлларымда
Өмет уты балкып торды.
Әй Илаһым, рәхмәт Сиңа!

Кайчак егылып, курка калсам,
Юлда ятып калам, диеп,
Ярдәм кулың суздың миңа:
«Эшләрең күп, балам!» – диеп.
Әй Илаһым, рәхмәт Сиңа!

Мин бит Синең бер кисәгең,
Ак җан белән килдем Җиргә.
Чиста күңел, пакь җан белән
Кайтырмынмы хөкемеңә?
Әй Илаһым, ташламачы,
Ташламачы ярдәмеңнән!

---

* Роза Мөхетдинова көе.

## ШУНДЫЙ ДӨНЬЯ...

Бик гади ул Тормыш фәлсәфәсе:
Нәрсә бирсәң, шуны аласың.
Ут бирәсең килеп кешеләргә,
Яналасың икән, янасың.

Яналмыйсың икән, үзең кара:
Мәҗбүр итми беркем янарга.
Ә кем белә: тиештер син, бәлки,
Ташкын елга булып агарга.

Бар чүп-чарны тиештер син, бәлки,
Үзең белән алып китәргә.
Тирә-юньгә яшәү бирер өчен
Ком чүлләрен бакча итәргә...

Дөнья – төрле, кешеләр дә төрле –
Кемгә язган мәңге янарга,
Ә кемгәдер – утны сүндерерлек
Ярсу елга булып агарга...

## ТӘҢРЕ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

– Бу мизгелдә күпме җан иясе
Ялварадыр күзен төбәп, Ходам...
Минем дә бар Сиңа әйтер сүзем,
Мине дә бер колак салып тыңла!

– Мин бит беләм ниләр әйтәсеңне,
Ни әйтергә кирәк түгелен дә...
Күңелең белән сөйләш, күңелең белән, –
Мин туганнан бирле күңелеңдә!

## КЕШЕ БУЛЫП КАЛЫЙК

Бергә-бергә бер сукмактан йөрдек,
Үрләрне дә бергә-бергә мендек.
Бу дөньяда шактый күпне күрдек, –
Җиргә бит без сыналырга килдек.

Бергә-бергә күп хәлләргә тарыдык,
Арган чаклар булды, хәлдән тайдык,
Тормыш безне судан утка салды –
Бергә-бергә бер утларда яндык.

Моңарчы без сынатмадык бугай –
Моңа шаһит Кояш, йолдызлар, Ай...
Моннан соң да Кеше булып калыйк –
Ярдәмеңнән ташламачы, Ходай!

## ГӨЛЧӘЧӘК

*Р-га*

Сандугачлар сайрап торган иртәдә
Кояш белән сөйләшә бер Гөлчәчәк:
– Тирә-юньне ямьләү иде уйларым,
Нинди булыр икән минем киләчәк?

– Миңа ошый синең әйткән сүзләрең,
Бар нәрсәдән тик Матурлык эзләвең.
Киләчәгең матур булыр, гүзәлем,
Матур булса артта калган эзләрең.

Изгелекләр, матурлыклар җитмәсә,
Яшәүләрнең мәгънәсе ни җиһанда?
Иркәләсен күңелләрне, күзләрне –
Матурлыгың кешеләрдән кызганма!

# КОЯШКА ҮРЕЛӘМ!

*(Балалар өчен шигырьләр)*



## ЯРАТАМ!

Көмеш төсле тамчылар,
Бәллүр төсле тамчылар
Сикерешә түбәдән,
Сикерешә түбәнгә,
Тып-тып итеп,
Тып итеп,
Бар дөньяны бер итеп.

Күп тамчыдан күл булыр,
Күлле җир гөлле булыр.
Йөз меңләгән тамчылар
Әнә биергә чыга
Тып-тып итеп,
Тып итеп!
Бар дөньяны бер итеп.

Язның ямьле көнендә,
Бәхет теләп җиремә,
Әллә күңелем җырлый,
Әллә тамчылар җырлый
Чың-чың итеп,
Чың итеп,
Бар дөньяны бер итеп!
Тамчы җырын яратам!
Тамчы җырын яратам!
Яратам!
Яратам!
Яратам!

# ӨЕБЕЗНЕҢ КОЯШЫ

Бәлки, минем әбине
Сез дә белә торгансыз?
Әбиемне әби диеп
Әйтүе дә уңайсыз.

Минем әби япь-яшь әле,
Минем әби чип-чибәр.
Әбине күргән кешеләр,
Кызлар кебек син, диләр.

Әбием гел көлеп тора,
Йөзе нур сибеп тора.
Көне буе ничек армый –
Куллары биеп тора.

Минем әби
Шундый җылы, –
Иркәләнәсе килә,
Яннарында песи кебек
Сырпаланасы килә.

Түребездә балкып тора
Өебезнең кояшы.
Ничек менә әбием күк
Җылы, якты буласы?!

## КЫЗЫЛТҮШ

Тал башында, күзен кысып,
Утыра бер кызылтүш.
Үзе ялт та йолт карана:
Безне күзәтә, имеш!

Нигә безне күзәтә ул,
Нигә башын боргалый?
Әллә безнең уйнаганга
Кызыгып карап торамы?!

## КАЙТ, ПЕСИЕМ!

Ачтым өйнең ишеген –
Чыкты качты песием.
Күр әле син бу мутны –
Җирән купшы койрыкны!..

Эзләдем, арып беттем,
Әллә кайларга җиттем.
Юк кына бит песием,
Инде хәзер нишлием?!

Баш ватам да баш ватам:
Кайларда булган хатам?
Әллә инде мут кынам,
Җирән-ут койрык кынам
Эшсезлектән туйганмы?
Йоклап гарык булганмы?

Оятына көч килеп,
Эшләп ашыйсы килеп,

Орышмасыннар, диеп,
Эш эзләп киткән мәллә
Күселе бирәр өйгә?

Песи, песи, пескәем,
Яшел ялкын күзкәем,
Нишлим соң инде синсез?
Синсез шундый күңелсез!

Өйләрнең дә яме юк,
Ашларның да тәме юк.
Йөрмә инде мутланып,
Койрыгың сыртка салып.

Кайтып кер инде өйгә,
Болай йөрүләр нигә?
Эшне үзем табармын,
Сөеп кенә багармын
Яшел ялкын күзеңә,
Кайт, песием, кайт өйгә!

## ЧЕБЕН

Килә дә куна битемә –
Тәмам туйдырды чебен.
Тотыйм гына дигән идем,
Чыгарды миңа телен.

Аннан көлгәндәй итте,
Очып йөргәндәй итте.
Туйганчы бер үртәде дә
Тәрәзәбездән урамга
Очып чыкты да китте.

## КУЯН

Җыям, җыям, җыям да
Илтәм дустым Куянга.
Нәрсә илтә, дисезме?
Шуны да белмисезме?
Куян кишер ярата,
Кәбестәгә дә риза.
Куянның кызыл күзе
Чөгендергә дә кыза.
Күсе-тычканнар тотмый,
Куян ул песи түгел.
Кучтәнәчкә кишер-мишер
Кетә ул миннән бүген.
Гел уен да гел уен
Булмады быел уем.
Сулар сибеп үстердем
Кишер, кәбестә, суган...
Суганын алып тормам –
Суган яратмый Куян.

Менә шундый ул Куян –
Куян – ве-ге-та-ри-ан!

## БУРАН

Җил сызгыра,
Үрсәләнә,
Дулый буран.
Бөтен җир-күк,
Бөтен урам
Ап-ак буран
Белән тулган.
Үрсәләнә,
Дулый буран...

## КҮКЕ

Саныйсың да саныйсың –
Күке, ничек армыйсың?
– Күк-кү, – дисең, –
кук, – дисең, –
Алда гомерең күп, – дисең.
Җирдә барлык кешеләргә
Озын гомер телисең,
Имин гомер телисең,
Матур гомер телисең.
Шулай булгач, күке дустым,
Син шундый да әйбәттер,
Синең хакта, оясы юк,
Нәселсез ул, биләмче, дип
Сөйләүләре гайбәттер.
Әлбәттә, бу гайбәттер!

## КАР ЯВА ДА КАР ЯВА...

Кар ява да кар ява,
Рәхмәт инде карларга:
Юлларымны ак иткән,
Бөтен дөнья ялт иткән!
Рәхмәт инде карларга:
Безне көткән тауларга
Чыгарбыз менә тиздән
Чана шуып уйнарга.
Чаналарда «выжт» кына,
Чаңгыларда «выжт» кына
Рәхәтләнеп шуарбыз,
Көрткә кереп чумарбыз!
Эзләсеннәр аннары...
Рәхмәт сезгә, карларым!

## ТАВЫК

Коймада тишек табып,
Бакчага кергән тавык.
Кыт-кыт-кыт килгән була,
Кыланып йөргән була.
Түтәлләрдә казына,
Азган саен азына.
Карап-карап тордым да,
Юк мыекны «бордым» да,
«Тукта, дим, кызык итим
Бу юньсез җан иясен:
Икенчеләй түтәлләрне
Таптап-изеп йөрмәсен.
Хәзер мин аны тотам,
Койма аша ыргытам!»
Шуннан китте чабышу –
Әйтерсең лә ярыш бу!
Чабабыз пыр туздырып,
Бер-беребездән уздырып.
Ярты сәгатьләп чапкач,
Арып, әлсерәп беттек.
Түтәлне дә «эт иттек»,
Табылмый теге тишек.
Чыгалмагач тишектән,
(Ничекләр башы җиткән?!)
Тәмам алҗыган тавыгым
Уктай чыгып ычкынды
Ачык калган ишектән!..

## БАЛ КОРТЫ

Беркөн болында йөрдем,
Бик күп чәчәкләр күрдем.
Ниләр генә юк монда –
Безнең яшел болында!
Кызыл чәчәк, ал чәчәк,
Ак чәчәк тә күк чәчәк –
Шундый-шундый күп чәчәк!
Берсеннән-берсе матур,
Берсеннән-берсе тату.
Урын да тар, димиләр,
Бер-берсенә тимиләр.
Кычкырып сөйләшмиләр,
Әрләшми, тиргәшмиләр.
Бер-берсен яраталар,
Бөтен болын өсләренә
Хуш исләр тараталар.
Һәрберсенә җайлап кына
Бал корты килеп куна.
Бал кортларының җырыннан
Тирә-юнь гөжләп тора...
Ой!
Нечкә билле бер бал корты
(Әллә чәчкә дип белде?)
Миңа да килеп кунды.
Ә мин, ул очып киткәнче,
Селкенергә дә куркып,
Кузгалмый басып тордым.

## КУЯН ГОЗЕРЕ

– Бик авырта колакларым,
Тотма әле колагымнан!
Уф!
Ничек кенә котылырга
Бу малайның кулларыннан?!
Колагы озын дигәч тә,
Күзләре кылый дигәч тә,
Тырнагы үткен дигәч тә,
Шулай кыланырга ярыймы?
Әнә ул сусыл үләнне,
Кәбестә белән кишерне,
Баллы кызыл чөгендерне
Алдыма гына куялсаң,
Аннан күз алдымнан югалсаң,
Озын, матур колагыма тимәсәң,
«Әй, син, кылый күз!» – димәсәң,
Син китергән тәмле сыйны
Кетер-кетер кимерер идем,
«Җир йөзендә
Иң әйбәт малай
Бары ул!» – дияр идем.
Уф!
Тимә озын колагыма!

## УНБИШ ЧЫПЧЫК, БЕР ТУҢДЫРМА

Кышкы суык. Ап-ак кар.
Кар өстендә чыпчыклар –
Нәни тере йомгаклар.
Чык-чырык!
Чык-чырык!

Әйдә, сикереп җылыныйк,
Диешәләрдер инде,
Шуңа сикерешәләр,
Биешәләрдер инде...

Мин дә менә курыкмыйм
Суыктан.
Чыкмыйсың аны урамга,
Курыксаң...

Әй, син, чыпчык малае,
Ашыйсыңмы тундырма?
Тик карап аша, яме,
Томшыгыңны тундырма!

Унбиш чыпчык, сөенешеп,
Тундырмага ябырылды.
Әй чукыйлар тәрле яклап –
Ис китеп карап тордым:
Томшыклары ап-ак сөт.
Әй, Чык-чырык,
Борыныңны сөрт!
Ярты сәгать чукыгач,
Әллә инде ардылар,
Әллә туеп калдылар,
Очтылар да киттеләр.

Тундырманың яртысы
Ятып калды ак карда...
Карыннары бик ачса,
Тагын килерләр әле.
Чык-чырыклар ач булмас,
Айнур дуслары барда!

# ЯЗГЫ ӘКИЯТ

Көмеш тамчы,
Нишлим икән, диеп,
Кояшта елмаеп торды да
Тып итеп җиргә тамды.
Ә ул тамган җирдә
Җем-җем итеп ята иде
Бер күлдәвек.
Тамчы тамгач,
Кояшта көлә-көлә,
Тирә-юньгә
Әллә ничә тамчы чәчрәде.
Ә бит җиргә тамган иде
Нибары бер тамчы!..

# ЯЗГЫ ЯҢГЫР

Җирне дер селкетеп,
Күк бабай күкрәде.
Яшеннән коелган
Кылычын селтәде.
Күк бабай бик юмарт:
Җир дымга тиенсен,
Дип сипте иң эре
Бөртекле энҗесен.

# ЯҢГЫР

Күренеп тора: интеккән –
Җирнең ирене кипкән...
Су эчәсе бик килгән,
Яңгыр кирәк бүгеннән...
Шулай уйлавым булды,
Күкнең теге-е-е читеннән
Килде чыкты бер болыт
Ап-ак кар тавы булып.
Аннан каралды, тулды,
Кап-кара болыт булды.
Аннан соң ул «ишелде»,
Гүя күкләр тишелде:
Коеп та куйды инде!
Явып та куйды инде!..
Булды инде, булды ич,
Җир су эчеп туйды ич.
Шулай уйлавым булды,
Яңгыр да кинәт тынды.
Ялт итеп кояш чыкты,
Гөл керфекләрен үпте.
Күкнең бер як читеннән
Икенче як читенә
Бизәкле күпер элде,
Җиргә карады, көлде.
Җир юынды, коенды,
Яңа туган күк булды.
Рәхмәт сиңа, яңгыр дус,
Бик тә сизгер икәнсең.
Бүтән җирләрне әйләнгәч,
Тагын килеп китәрсең.

## КҮКЕ РӨХСӘТ ИТТЕ

Мин бу көнне җәй башыннан
Түземсезлек белән көттем.
Суга чумсаң да ярый, дип,
Күке үзе рөхсәт итте.

Әй йөздем соң рәхәтләнеп:
Сагындырган Идел суы!
Күке үзе рөхсәт итте,
Курыкмыйм мин – тими суык.

Мин яратам сине, Күке,
Җирдә, ярый, син дә барсың.
Суда күпме тамчы булса,
Шуның кадәр рәхмәт яусын!

Ялварамын Табигатькә,
Сиңа озын гомер теләп.
Җирдә кеше яшәгәндә,
Син бит аңа шундый кирәк!

## ЧӘЧӘКЛӘР

Көн буе бакчадан кермимен,
Әйтерсең хәзинә эзлим мин.
Мең төрле чәчәкләр күзлимен,
Юк, гөлләр, мин сезне өзмимен.

Сез, гөлләр, шундый да сөйкемле,
Нәфисләр, хуш исле, горурлар.
Кайчан соң мин чәчкән орлыклар
Бакчага ямь биреп торырлар?!

## ТАҢ АЛДЫННАН

Җем-җем килә күлнең өсте –
Кояш алтын нурга манган.
Таңда йокы тәмле була –
Урман да йокыга талган.

Тәмле төшләр күреп йоклый
Күл буеның камышлары.
Тып-тын әле – ишетелми
Кошларның да тавышлары.

Кичен концерт биреп арган –
Бакалар да тынып калган.
Нәрсә көтә икән бар да
Тып-тын калып туар таңнан?!

## ЯМЕ АРТТЫ КҮҢЕЛЕМНЕҢ

Алтын кояш әйтерсең лә
Назлы, йомшак әни кулы.
Башларыннан сыйпау белән
Мамык төсле җылы нуры,

Үсте гөлләрем, яшәрде,
Аннан гөрләп чәчәк атты.
Яме артты күңелемнең,
Бар дөньяның яме артты.

Кояш нуры – әни кулы,
Кагылды да күңелемә,
Чәчкә булып кереп калды
Йөрәгемнең иң түренә.

# КАМ-КАМ

*(Бик кыска, әллә моңсу,*
*әллә күңелле әкият)*

Шулай берзаман, туган,
Кам-Кам дигән Боз булган.
Әллә малай, ди, шунда,
Әллә инде кыз булган...

«Кам-Кам түгел,
Там-Там син!» – дип,
Моннан һаман көлгәннәр,
Теңкәсенә тигәннәр.
Әллә болай үртәгәннәр,
Әллә серен белгәннәр...

Кам-Кам күңелсезләнгән,
Нишләргә дә белмәгән.

Аннан көлә башлаган –
Үпкәләвен ташлаган.
Көлә торгач, эрегән,
Эри торгач, кимегән.

Боз камчысы Кам-Камнан
Бер су тамчысы калган.
Ул да озак тормаган –
Тып итеп җиргә тамган.

Шулай эргән дә беткән,
Гөрләвеккә кушылып,
Елгага агып киткән...

Шулай итеп шул, туган:
Кам-Кам дигән Боз булган.

Әллә малай, ди, шунда,
Әллә инде кыз булган...

Кыз булгандыр ул, туган, –
Шулкадәр көлмәс иде,
Бик тиз эремәс иде...

## КОЯШКА ҮРЕЛӘМ

Гөлкәем, тибрисең,
Тибрисең җилләрдә.
Син нәрсә сөйлисең
Ул назлы җилләргә?
Үлмәдең, сулмадың.
Суздың да кулларың,
Кояшка үрелдең.
Ул сипте нурларын,
Син ямьгә күмелдең.
Сокланып туймадым,
Шулвакыт уйладым:
Мин дә бит синең күк
Яшәргә туганмын.
Яктыга үреләм,
Сузам да кулларым,
Чөнки мин синең күк
Яшәргә туганмын!

## БОЛЫТ МИҢА БУЛЫШТЫ

Кояш шундый кыздыра –
Кызган мичтән уздыра!
Ә бакчада җирҗиләк –
Кызарып пешкән бигрәк.
Шундый да пешкән инде,
Изелеп төшкән инде.
Җиләкләрне кызганам –
Җыеп, тырыска салам.
Ә күктә кояш кызган,
Нурларын миңа сузган.
Кара инде син, кара,
Бигрәк юмарт кылана!..
Җыя торгач, арыдым,
Манма су булдым, пештем.
Шул җир җиләкләре кебек,
Үзем дә изелеп төштем.
Арыдым ла, арыдым,
Тәмле җиләкләре өчен
Рәхмәт әйтеп кояшка,
Мин болытка ялындым:
– Инде күп тә калмады,
Ярдәм итә күр, дустым:
Каплап торчы кояшны,
Тутырганчы тырысны!
Болыт мине аңлады,
Якын итте, булышты:
Каплап торып кояшны,
Җиләгемне «җыешты»!

## КҮҢЕЛЛЕ!

Җир кызына туры карап
Кояш-егет көлгәнгәме,
Яңа ачылган чәчәк кебек
Ал таң туып килгәнгәме,
Белмим,
никтер бик күңелле миңа.

Әллә инде көмеш чыклар
Җем-җем итеп күз кысканга,
Әллә инде Җиркәемне
Охшатканга Гөлстанга,
Белмим,
никтер бик күңелле миңа.

Зәңгәр күктә кардай ап-ак
Бөдрә болыт йөзгәнгәме,
Игенкәйләр таң җиленең
Иркәләвен сизгәнгәме,
Белмим,
никтер бик күңелле миңа!

## УРМАНДА

Көрән эшләпә кигән,
Әллә күрмәс дип белгән?!
Яфрак астына кергән.

Аһ, хәйләкәр, аһ, наян,
Уемны белгән каян?!

Тик барыбер күрдем бит,
Кемлегеңне белдем бит!

Менә кисеп алыйм да,
Кәрзинемә салыйм да,
Кайтарыйм әле өйгә,
Бирим әле әбигә!..

## ЮКӘ БЕЛӘН КАЕН

Юл читендә юкә белән
Каен тора басып.
Тын калганнар, әйтерсең лә
Бер-берсенә гашыйк...

Икесе дә яшьләр әле,
Икесе дә яшел...
Каен-кызның зифа буен
Күмер итте яшен.

Юкә-егет түзә алмады,
Җиргә иде башын.
Йомшак җилләр генә исте,
Сөртеп энҗе яшен...

## ЭШКӘ ОСТА, СҮЗГӘ КЫСКА

Әнә ята бүрәнә –
Әйдә, көчең җәлләмә –
Күтәр әле нығытып.
Күтәр дә шунда ыргыт.
Хәзер инде карагыз:
Кулга ышкы алабыз,
Бер, ике, өч!
Бездә – көч.
Ялт итте бит бүрәнә,
Елмаеп ята әнә!
Кабык киемен салгач,
Сап-сары булып калгач,
Нәкъ сабый бала кебек,
Тик карап ята көлеп.
Нигә көлә икән ул?

Шуны белә икән ул:
Ул кешеләргә кирәк,
Әйдә, өй салыйк тизрәк!
Бабайлар һәм әбиләр,
Апалар һәм абыйлар,
Әниләр һәм бәбиләр
Яңа өйгә керсеннәр,
Алар да бер көлсеннәр,
Рәхәтләнеп йөрсеннәр,
Тик шунысын белсеннәр:
Бу булыр оста эше –
Рәхмәт укысын кеше!
Бүрәнә бит үзе генә
Берни эшли алмас иде,
Кабыгын да салмас иде,
Үзе өй салмас иде,
Урыныннан да кузгалмас иде.
Тагын монда килегез,
Ни эшләнә – күрегез:
Алъяпкыч япкан оста,
Тирә-юньдә йомычка
Тегендә оча,
Монда оча.
Пычкы әйтә: чыж-чыж,
Ышкы йөри выж-выж,
Балта тукый: тук-тук,
Йөрмәгез монда эшсез,
Ялкауларга урын юк...
Юан-юан бүрәнәләр
Такталарга әйләнгәннәр.
Бар да эшчән,
Бар да җитез,
Ә останы күрегез сез:
Йөзләр-күзләр көлеп тора,
Куллар җилдәй йөреп тора:
«Без ясаган шкафларда

Савыт-саба чылтыр-чылтыр.
Без ясаган урындыклар
Ныктыр, ныктыр.
Безнең кулдан үткән рамнар
Җанлы сыман – җырлап тора,
Урамнарны ямьләндереп,
Тирә-юньне нурлап тора».
Кешеләрне сөендереп,
Менә шулай эшли оста.
Бигрәк җитез – коеп куя,
Эшкә оста, сүзгә кыска.

## ӘБИЕМ КИЛГӘН!

Өйгә кайтсам, өй балкыган –
Йортка нур иңгән.
Ерак җирне якын итеп,
Әбием килгән!

Үзен ничек сагынганны
Белгән ул, белгән.
«Күрим әле бәбкәмне!» – дип,
Әбием килгән!

# ТАТАРЧА БЕЛМӘҮЧЕ КӘҖӘЛӘР

Шундый безнең Алиябез:
Үлеп әкият ярата.
Сөйли аны әнисе дә,
Сөйли аны Марат та...

Әкият иле Алиянең
Туган иле диярсең!..
Бердәнбер кызың сорагач,
Әллә ниләр сөйләрсең.

«Козлятушки, дитятушки,
Ваша мать пришла –
Вам молочка принесла...»
Кәҗә шулай җырлый, диеп
Сөйләп китә әнисе.
Урысчалап такмаклауга
Алия соң ни дисен?!

Тыңлап-тыңлап тора да ул
(Тыңлый белә ул үзе!),
Әнисе сөйләп бетергәч,
Әйтеп куя үз сүзен:

– Бу кәҗәләр бер генә дә
Татарча белмиләрме?
Татар телен белмәгәнгә,
Урысча сөйлиләрме?

## ДӘҮ ӘНИ

Песи булып мияуладым,
Сыер булып мөгрәдем.
Әтәч булып та кычкырдым,
Күгәрчендәй гөрләдем.

Тавык булып кыткылдадым,
Күкәй генә салмадым.
Эт булып та өрдем инде,
Үзем бер дә армадым...

«Һау-һау!» – дигәч, Гүзәлиям
Елавын да онытты.
Кая китте күз яшьләре –
Танып булмый оныкны...

Бишектә бәби еласа,
Ни кирәген беләбез:
Елау да юк, ару да юк, –
Икәүләшеп көләбез.

## КЕМГӘ «КЫЗЫМ» ДИЯРСЕҢ?

– Җимешем син, матурым син,
Алтын бөртегем минем.
Ашап-ашап, ашап-ашап,
Ашап бетерер идем...

Яратуга түзалмыйча,
Әнисе шулай сөя.
Кара күзләрен тутырып
Карап тора Алия:

– Мине ашасаң, әнием,
Кемне шулай сөярсең?
Кемне шулай яратырсың,
Кемгә «кызым» диярсең?

## ТАПКЫР КЫЗ

– Хәзер, кызым, син мине
Яратасың, сөясең.
Әнием, дип, алтыным, дип,
Битләремнән үбәсең.

Картайгачтын, аргачтын,
Күзлек киеп алгачтын,
Бу маңгайны, битләрне
Җыерчыклар саргачтын,

Чәч агаргач, бил бөкрәйгәч,
Ямьсезләнермен инде,
Җимеш кебек татлы булмам,
Тәмсезләнермен инде...

Шулчак кем диеп дәшәрсең?
Мин соң ничек яшәрмен?
– Бер дә борчылма, әнием,
«Әбием» дип дәшәрмен.

## ӘЗЕР ҖАВАП

– Әй, кызым, кызым минем,
Кызым, йолдызым минем.
Уятмасаң, йоклар идең,
Ахры, көнозын, – димен. –

Әллә кайчан сикереп торды,
Әнә кара Маратны!
Күп йоклаган кызларны бит
Малайлар да яратмый.

Андый кызларны әтиләр
Бакчадан да алмыйлар.
Алиянең җавап әзер:
– Ә мин анда бармыйм да!

## КЫЗЫП КИТТЕ АЛИЯ

Алиягә дәү әнисе
«Бәбекәем» дип дәшә.
Әтисе дә, әнисе дә
Үзебезчә сөйләшә.

Урысчасы бераз аксый, –
Нихәл итсен Алия?
Бүтән телләр качмас әле,
Ана теле баш өйдә.

Алиянең теле дә бит
«Әннә» диеп ачылды.
Ана телен яратмый соң,
Йә, әйтегез, кайсыгыз?

Бүтән телләр дә өйрәнер,
Үсә төшсен Алия.
Ә хәзергә ана телен
Судай эчсен Алия.

Бакчаны бик ярата ул,
Ярата апасын да.
Кайчакларны килми хәтта
Бакчадан кайтасы да.

Тик шулай да беркөн менә
Кызып китте Алия,
Үзен-үзе булә-булә
Тезеп китте Алия:

– Татарча гына сөйләшә,
Гел татарча орыша:
Гөлназ апа бер генә дә
Белми, ахры, урысча...

## ЮАТУ

Марат инде җиде яшьтә,
Алиягә өч кенә.
Үзе кечкенә булса да,
Эче тулы төш кенә.
Дөнья күргән әбиләр күк –
Алдап булмый һич менә.
Әниләре әйткән иде
Әле бүген кич кенә:

– Нишләтергә инде сезне,
Тыңламыйсыз һич менә.
Иртән чыгып китәрмен дә
Кайтмам, ахры, кич белән.
Миңа мондый тыңлаусызлар,
Елаклар кирәкми лә!
Әни сүзен тыңлый торган
Балалар кирәк миңа.

Ничек инде ул әнисез,
Ничек инде ул алай? –
Маратның ике күзеннән
Мөлдер-мөлдер яшь тама.
Кем иркәләп уятыр соң,
Әни булмагач өйдә?
Кем пешереп ашатыр соң
Тәмле-тәмле әйберләр?

Марат шулай елап тора,
Алия уйламый да.
(Ул бит инде дәү үскән кыз, –
Дәү кызлар еламыйлар!)
Әле абыйсын юата:
– Кайта, кайта әнием!
Бездән башка торалмый ул,
Курыкма син, абыем!

## БАКА ТУЕ

Су буеннан, кош тоткандай,
Кайтып керде Алия:
– Бу бака балаларының
Юк икән әтиләре дә,
Юк икән әниләре дә.

Мин аларны кызгандым,
Җыеп чиләккә салдым.
Әйдә, бездә торсыннар,
Безнең бака булсыннар, –
Дип, Алия идәнгә
Куйды яшел чиләген.

Шуннан әллә нишләп киттем:
Ярылдымы йөрәгем?
Күләргәме, еларгамы?
Нишлим икән? Уф, үләм! –
Бөтен идән тулды шунда
Бармак башы хәтле генә
Бака малае белән.

Шуннан ни булды, дисез?
Әйтмәсәм, һич белмисез!
Кыш буена рәхәтләнеп
Бака хорын тыңладык.
Кайчакларны үзебез дә
Хорга кушылып җырладык:
«Бака-ка-ка, бака-ка!
Без бакалар яратабыз,
Алар безне ярата.

Бака-ка-ка, бака-ка!
Бака-ка-ка, бака-ка!»

Кыш буена өебездә
Без бик кызык яшәдек.
Шундый кызык яшәдек –
«Бака туе» ясадык...

## АЛИЯ «КӘҖӘЛӘНӘ»

– Мин бакчага бармыйм бүген,
Арыдым, туйдым инде.
Әнием, дим, бүген генә
Өйдә утырыйк инде?!

– Алай булгач, утыр үзең,
Барма инде бармасаң...
– Үзем генә куркам шул мин,
Барыйк инде алайса...

## БАКЧАГА БАРАСЫ БАР

– Әйдә, кызым, тор инде, тор,
Соңга калдык, тиз киен!
– Әйттем ич инде, әнием,
Мин бик торыр идем дә бит,
Күзем ачылмый, дидем...

## БОТКА ТҮГЕЛ...

– Нигә ашамыйсың, улым,
Әллә ботка артык кайнар?
– Юк, әнием, ботка түгел,
Никтер менә кашык кайнар...

## АЛТЫН СУКМАК

Су өстендә алтын сукмак:
Кояшта җем-җем итә.
Белсәң иде, ул якты юл
Кайларга кадәр илтә?

Икенче ярга кадәрме,
Диңгезгә койганчымы?
Күзләремне ала алмый
Карадым туйганчы бер.

Матурлыкта һич тиңе юк –
Кояш бит салган аны.
Шулвакыт күкне кап-кара
Болытлар каплап алды.

Тагын бер карадым суга –
Алтын сукмак югалган.
Күңелемдә ул кузгаткан
Дулкыннар гына калган.

## ДӨРЕС АҢЛАГАН...

Ашыккан ашка пешкән, ди.
Әбинең алтын сүзләрен
Әле генә төшендем:
Әни бүлеп биргән ашны
Кабаланып капкан идем,
Авызымны пешердем!..

## ТЕЛЕФОН

Әнисе кайтканны көтеп
Алия тәмам арды.
Тәрәзәдән карый-карый
Инде күзләре талды.

Кинәт – чылтыр-р! Марат барып
Телефонга ябышты.
Ур-ра! Ур-ра! – Трубкада
Әниләре тавышы.

– Менә әни белән сөйләш, –
Диде Марат абыйсы.
Шундук таныды Алия
Әнисенең тавышын.

Тавышы бар, үзе кайда? –
Аптырады Алия.
Кычкырып елап әнисен
Таптыра бит Алия!

Марат тәмам хәлдән тайды,
Алияне юатып.
Аптырагач, сүтеп салды
Телефон аппаратын.

Шөрепләр китте тәгәрәп,
Әнә ята капкачы.
Менә ята трубкасы,
Менә монда тартмасы...

Ватык телефонны күргәч,
Тынып калды Алия.
Әни дә юк, телефон да –
Тынычланды Алия.

## КАРАДЫМ ДА КАРАДЫМ...

Бүрене дә карадым,
Куянны да карадым,
Карадым да карадым.
Әле тагын карар идем...
Ярый, җитәр, ятыйм инде, –
Телевизор аргандыр...

## АЙНУР ҮПКӘЛӘДЕ

Ап-ак кына, йомшак кына
Кар явып үткән кичтән.
Мондый матур, йомшак карны
Ул көтә иде күптән.

Тәгәрәтеп җепшек карны,
Ясап куйды Кар бабай.
Менә, малай, бабай инде –
Бар бабайларга бабай!

Иртәгесен Айнур, торып,
Тәрәзәдән караса,
Кар бабайдан җилләр искән –
Эреп беткән ләбаса!

Айнур аңа үпкәләде,
Үзен ташлап киткәнгә:
«Чын кыш түгел икән лә бу –
Алдакчы кыш икән лә!..»

## БИК ЯРАТА МИНЕ ЭШ...

Әллә үзен яратканга –
Бик ярата мине эш.
Мин барын да эшләргә,
Мин өлгерергә тиеш!

Кызлар эше диеп тормыйм –
Савыт-саба да юам.
Әнием эштән кайтуга,
Табын әзерләп куям...

Тавык чүпләсә дә бетми
Өй эше, ди әнием.
Булышмыйча нихәл итим –
Кызы юк бит әнинең!

## ҮСӘСЕМ БАР...

Эшчән кеше тиз үсә, ди, –
Белми әйтмәс әнием.
Үсәсем бар: мин бит әле
Төпчек улы әнинең.

Кушканны да көтми эшлим –
Бик үсәсем килә ич!
Көн дә үсәм – әниемә
Зуп-зур егет кирәк ич!

## ҖИҢЕЛМЕНИ?..

– Сөтне каян алалар,
Беләсезме, балалар?

Айнур әйтте: – Мин беләм!
Башта каймак алалар,
Аннары су салалар,
Аннары болгаталар –
Килә чыга тәмле сөт...
Моны ишеткәч, һәммәсе
Рәхәтләнеп көлеште.

Ә ник әле көләргә?

Болыннарда йөрмәгәч,
Сөтбикәне күрмәгәч,
Каян белсен ди Айнур
Сөтне каян алганны?!
Җиңелмени аеруы
Булган хәлдән ялганны...

## КОШЛАР ТУЕ

Җимлек ясады Айнур,
Шундый матур җимлеге!
Кызылтүшләр, песнәкләр
Белсен әле кемлеген!

Коштай очып, канатланып
Чыгып китте урамга –
Үзе ясаган җимлекне
Талга элеп куярга.

Иртәгесен ниләр күрсен! –
Вәт тамаша, вәт уен! –
Әллә сабан туемы бу?
Юк ла, бу кошлар туе:

Бөтен урман кызылтүше,
Бөтен урман песнәге –
Бар да шунда җыелган,
Авыз итик әле, диеп,
Айнур дусның сыеннан...

Айнурның бит дуслары да
Үзе кебек уңганнар:
Иртәгесен ботак саен
Җимлек элеп куйганнар!

Бу ни гаҗәп хәл бу тагын?
Ни тамаша, ни уен?
Әллә сабан туемы бу?
Юк ла, бу кошлар туе!

Бөтен урман кызылтүше,
Бөтен урман песнәге –
Бар да шунда җыелган,
Авыз итик әле, диеп,
Дусларыбыз сыеннан.

Чыпчыклар да очып килгән,
Күгәрченнәр җыелган...
Кем соң инде баш тартсын ди
Шундый кунак сыеннан?!

## КЫЗЫК ИКӘН...

Кыш бабай ул саран түгел –
Кардан таулар өеп куйган.
Юл ярулар җиңелмени
Кар көртләре арасыннан?!

Зарлана дип уйламагыз, –
Көне нинди матур бүген!
Кош тоткандай куанамын,
Тигез ике эзне күреп.

Үзем салган эзләр бит ул,
Иң беренче салган эзләр!
Мондый көнне ничек түзсен?!
Дусларым да чыгар тиздән.

Акбүз аттай бураннарның
Ялларына ябышырбыз;
Бергә-бергә шаян-елдам
Җилләр белән ярышырбыз...

Очып кына үтеп киттем
Алда торган текә тауны...
Кызык икән, рәхәт икән
Юлны үзең салулары!

## УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ҮСӘМ МИН

Курыкмыйм мин бураннан –
Кайтып кермим урамнан.
Өйдә нәрсә бар анда?
Бөтен кызык урамда –
Бөтен кызык буранда.

Авылыбыз да ап-ак,
Урамыбыз да ап-ак.
Шәһәрнеке кебек түгел –
Буранybыз да ап-ак.

Яратам мин буранны,
Ап-ак карлы урамны.
Ап-ак көртләргә чумам,
Ак малай булып чыгам.

Ак кар булып торелэм,
Җилләр булып исәм мин.
Бураннар белән ярышып,
Уйный-уйный үсәм мин.

## КИЛМИ КАЛМАС ӘЛЕ УЛ...

Күрдем бүген бер песнәкнең
Тәрәзәне какканын,
Күрдем, эзләп аргач кына,
Бер бөртек җим тапканын.
Тәрәзәмне ачкан идем,
Кер, дип тә дәшкән идем,
Ут булды да юк булды –
Очты китте песнәгем!
Бигрәк инде! Шундый куркак
Булырга ярый микән?
Тагын килер микән песнәк?
Ә мине таныр микән?..
Песнәкләрне яратканны
Белми калмас әле ул,
Күмәч белән сыйланырга
Килми калмас әле ул!

## МИН АНДЫЙ МАЛАЙ ТҮГЕЛ!

Өйдә әни: «Бу салкында
Йөрмә, – ди, – туңарсың», – ди.
Ә урамда җил өркетә:
«Кереп кит, еларсың», – ди.

Биек таулар: «Без биек, – ди, –
Менмә, – ди, – егылырсың.
Барыбер, – ди, – ярты юлдан
Кирегә борылырсың...»

Һәрберсенең үз туксаны,
Һәрберсенең үз сүзе.
Соң мин дә бит егет кеше,
Мин үзем дә үзсүзле!

Соң бит алар дөрес әйтми,
Соң бит ул алай түгел!
Егылганга елап тормам –
Мин андый малай түгел!

Суыктан да куркып торсам,
Адым саен егылсам,
Биек тауга меналмасам,
Ярты юлдан борылсам.

Мин нинди егет булыйм? –
Мин бит әтием улы!

## ДӘҮДЕР ҖИЛНЕҢ АВЫЗЫ

Әти белән урманга
Киттек чаңгы шуарга.

Урманга әле ерак,
Барабыз кырлар буйлап.

Барабыз җайлап кына,
Көртләрне сайлап кына.

– Кырлар бит такыр калган,
Карын җил ялап алган, –

Ди әти, үзе көлә
(Ул инде барын белә!)

Дәүдер җилнең авызы –
Кара син ул явызны!

Шундый да юньсез булырга,
Шундый да комсыз булырга
Ярый димени инде?!

# АКЛАНДЫ...

– Әни, бүген «бишле» алдым!
Апа мине мактады
Бөтен класс алдында!

– Тагын нинди билге алдың?
– Тагын... тагын...
Әй, «икеле» алдым ла...

– Анысы ник инде, улым?

– Әни, син бик кайгырма
(Айнур бераз уйланды):
Минем «ике» нәни генә,
Менә моны-ың чаклы гына...
Рәмзинекен күрсәң иде,
Шундый симез –
Дәфтәренә сыймады!..

# ЭЧТӘЛЕК

## Кеше булып калыйк!

«Җиргә әллә чык тамчысы...» . . . . . . . . . . . . . . 6
«Суга туймас гөлләр сыман...» . . . . . . . . . . . . 7
Кызлар сагышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Яшьлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
«Айның әле яңа гына...» . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Бу өч көнлек дөнья . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Сызла, Йөрәк, сызла! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Акыл белән Йөрәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Быелгы яз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Утның яшисе килә... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Белдем – белмәдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Ник болай еш бәргәләнә йөрәк?..» . . . . . . . . . 12
«Бу дөньяның даны...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Каргаларны өнәп бетермиләр...» . . . . . . . . . . 12
Гаҗәп!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
«Кузгатмагыз иске яраларны...» . . . . . . . . . . . 13
«Үргә мендем, дип куанма...» . . . . . . . . . . . . . 13
«Без көн саен шулай юанабыз...» . . . . . . . . . . . 13
Тик яратып... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Болын тулы чәчәк...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Беркем белми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
«Табигатьтә бар нәрсә дә камил...» . . . . . . . . . 15
«Шатлыкларың, кайгыларың өчен...» . . . . . . . . 16
«Куркытмагыз әле тәмуг белән...» . . . . . . . . . . 16
«Җырларың ник моңлы? – дип сорыйлар...» . . . . 16
Бозлы таулар иләндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Тауга менеп барам... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Тормыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Кызыл каурый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Юлда мин... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
«Еларлык сәбәп болай да...» . . . . . . . . . . . . . 20
«Алсуланып пешкән алмага...» . . . . . . . . . . . . 20
«Сәер бу уйлар йомгагы...» . . . . . . . . . . . . . . 20
Яратыгыз мине шушы килеш! . . . . . . . . . . . . . 21
«Чынбарлык ул шундый...» . . . . . . . . . . . . . . . 21
«Кояшлы утраулар эзләп...» . . . . . . . . . . . . . . 21

Иң зур бәхет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
«Табигатьне, имеш, үзгәртәбез...» . . . . . . . . . . 22
Җырым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
«Туры юлым таш яра, дип...» . . . . . . . . . . . . 23
Әтнәм – туган яккаем . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Сагыну дәрьялары тирәндер... . . . . . . . . . . . . 25
Кемнәр әйтте әле... . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Кара әле тутырып күзләремә... . . . . . . . . . . . 26
«Ак болытлар, күрче, нинди нәфис...» . . . . . . . . 26
«Чәчләремнән назлап иркәләгәч...» . . . . . . . . . 27
Сагыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Бик ямансу булыр әле безгә... . . . . . . . . . . . 29
Кышларның бураннары . . . . . . . . . . . . . . . . 30
«Ачу...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Тик үземчә генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Минем өчен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
«Бер газапсыз тумый һичнәрсә дә...» . . . . . . . . 31
Тик җыр гына булыр юлдашым . . . . . . . . . . . . 32
Мин сине шундый сагындым . . . . . . . . . . . . . 32
Яктырып китте күңелем... . . . . . . . . . . . . . 33
Матур буласым килә . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Чайпалырмын, түгелермен... . . . . . . . . . . . . 34
Рәхмәт сиңа, Бәхет кошым! . . . . . . . . . . . . . 35
Бәхет өчен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
«Безнең урамда да бәйрәм булыр...» . . . . . . . . 36
«Күктән йолдыз булып атылам...» . . . . . . . . . . 37
«Бүтән нәрсә миннән эзләмәгез...» . . . . . . . . . 37
Аналар йөрәге җылысы . . . . . . . . . . . . . . . 38
Бер үгет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Китү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Нигә болай? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Бик сагынам, әнкәй, мин сине . . . . . . . . . . . 42
Ана сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Ышандыр! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Елмаеп тор яннарымда . . . . . . . . . . . . . . . 44
«Кеше кайгысына кайгыру ул...» . . . . . . . . . . 44
Без икебез пар кебек... . . . . . . . . . . . . . . 45
«Каргый күрмә караңгыны...» . . . . . . . . . . . . 45
«Нишләп андый булмаганмын...» . . . . . . . . . . . 46
«Беребезне беребез елатырга...» . . . . . . . . . . 46

«Җәйләр кыска, кышлар озын булды...» . . . . . . . . . . 47
Ялкын теле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Өйрән... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Ишетерме Ходай? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
«Байлыкка мин гомер кызыкмадым...» . . . . . . . . . . 50
Без – кешеләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Көтәм... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
«И хыялый, тиле бала...» . . . . . . . . . . . . . . . . 52
«Кайгы – озын, шатлык – мизгел...» . . . . . . . . . . . 53
«Язмыш какса, мин бигрәкләр...» . . . . . . . . . . . . 53
Ап-ак кәгазь. Каләм. Кара . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Нишләтәсез йөрәкне? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Уйлама, дисең... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Кояшка! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
«Шулкадәр дә моңсу – йөрәккәйләр...» . . . . . . . . . . 55
«Кайчакларда, артык йомшап китеп...» . . . . . . . . . 56
Аңлый алмыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Ышаныгыз! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Өмет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Теләсә ни уйласыннар минем хакта...» . . . . . . . . . 58
Таңга карап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Ни диярләр икән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Хөкемдар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Боздай карашларны күрдем . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Күңел күге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
«Зарларыңны җилгә сөйлә...» . . . . . . . . . . . . . . . 60
Киңәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
«Көн белән төн чиратлашып тора...» . . . . . . . . . . . 61
«Мин туганмын сугыш беткән елны...» . . . . . . . . . . 62
Җирне сагынып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
«Мин яратам утны, суны, җирне...» . . . . . . . . . . . 63
«Бу дөньяда бар да үз урынында...» . . . . . . . . . . . 63
Безнең җырлар нинди булыр икән? . . . . . . . . . . . . 64
Соңгы яфрак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
«Ни булган бу Табигатькә...» . . . . . . . . . . . . . . 65
«Баш очында...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Каеннарның ак яктысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
«Күз яшьләре ява Табигатьнең...» . . . . . . . . . . . . 68
Хыял уты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
«Су буенда йөрим өзгәләнеп...» . . . . . . . . . . . . . 69

«Каен кызы ник боеккан?..» 69
«Әкрен генә менеп киләм...» 70
Мин гашыйкмын... 70
«Шау-шулардан туеп...» 71
Язмыш сине җирдән аермасын... 72
Яр астында кояш баеды 73
Мөлдерәмә тулы күңелем 74
Йөгерә-йөгерә барам... 75
«Күзләреңне каплап алса...» 76
«Дөньяга көлеп-елмаеп...» 77
Тыймагыз йөрәкне! 77
«Назга, иркәләүгә туймас...» 78
Күбәләк 79
Гаҗәп түгел 80
«Биш пар күзне йокы ала алмый...» 81
Нәрсә әйтим? 81
«Карурманда килә югаласым...» 82
«Нигә тыныч була алмый минем күңел?..» 83
Диңгез димә... 83
Күрәсеңме? 84
«Сөенсеннәр, әйдә...» 84
Хәтер 85
«Акбүз атым, әй, ярсыган...» 85
«Дөнья мәшәкатьләреннән арып...» 85
«Бер кителсә, дөнья гел кителә...» 86
Эндәшмим 86
«Көзләр килде күңел кырларыма...» 87
«Аңлый алыр микән мине...» 87
Халәт 88
И йөрәгем!.. 88
«Су болгану гаҗәпмени...» 88
Ачуланма, диңгез! 89
Йөгереп чыктым урамнарга 90
Әйтерсең лә 90
Рәхмәт! 91
Арткан саен... 92
«Кеше башы саен хәсрәт...» 92
«Күңелемнең кылдан нечкә чагы...» 93
Ә яр тыныч... 94
Киереп ач, әйдә, тәрәзләрне... 94

«Дулкынлана диңгез, күбекләнеп...» . . . . . . . . . . 95
Әдрән диңгез! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
«Мин, кешеләр, сезгә үпкәләмим...» . . . . . . . . . . 96
«Каян гына алыйм...» . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Хыял, нигә алдадың? . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Ут . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Теләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Яшен булып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
«Болганчык су төсле...» . . . . . . . . . . . . . . 99
Китмим әле яшьлегемнән . . . . . . . . . . . . . 100
Китмә, Кояш! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Шагыйрь гомере . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
«Белмим бугай сине...» . . . . . . . . . . . . . . 102
«Баш очымда болыт куера...» . . . . . . . . . . . 102
Җыр булып калдың... . . . . . . . . . . . . . . . 103
Аккош моңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Ак бураным – ак канатым . . . . . . . . . . . . . 104
Минем дөньям . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Ак розалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
«Хушлашмый да китәм...» . . . . . . . . . . . . . 107
«Югалып калган чакларда...» . . . . . . . . . . . 108
Болыт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
«–Йөзең көләч, ә ник әле...» . . . . . . . . . . . 108
«Дөнья читтән карап тора...» . . . . . . . . . . . 108
«Бер дулкыны, димим, зур диңгезнең...» . . . . . . 109
Әгәр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
«Син шомланма, тиктән сискәнешеп...» . . . . . . 109
«Хыял бераз хәйләли дә...» . . . . . . . . . . . . 109
Авылым урамы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Балачак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Алтын кояш, зәңгәр кыңгырау... . . . . . . . . . 111
«Тәрәзәмә чиртә язгы яңгыр...» . . . . . . . . . . 111
Туган җирдә җаным тыныч . . . . . . . . . . . . . 112
Кар вальсы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
«Кояшның бер нуры булсам...» . . . . . . . . . . . 114
Гомер ике килми . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114
Әнкәй җаны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Хәерле көн телим . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Бәби күтәргәннәр әниләр... . . . . . . . . . . . . 116
Әйт, әнием, җилләргә . . . . . . . . . . . . . . . 117

И әнием!.. 117
. . . . . . 118
«Бертуктамый, армый-талмый...» . . . 119
Улым бар бит минем . . . 119
Улларыма . . . 120
Елама син, улым!.. . . . 121
Бердәнберем син минем . . . 122
Уятмагыз юкка балаларны! . . . 122
Дөньяганиләр булган? . . . 123
Иң зур җиңү . . . 123
Каен . . . 124
«Акыллылар нык кубәйде...» . . . 124
Тилмертмәгез гөлләрне! . . . 124
Китмәс иде... . . . 125
Давыл килә... . . . 125
Җирне ямьләп торган гөлне . . . 126
Әй Илаһым, ташламачы... . . . 127
Шундый дөнья... . . . 127
Тәңре белән сөйләшү . . . 128
Кеше булып калыйк . . . 128
Гөлчәчәк . . .

**Кояшка үреләм!** 130
Яратам! . . . 131
Өебезнең кояшы . . . 132
Кызылтүш . . . 132
Кайт, песием! . . . 133
Чебен . . . 134
Куян . . . 134
Буран . . . 135
Күке . . . 135
Кар ява да кар ява... . . . 136
Тавык . . . 137
Бал корты . . . 138
Куян гозере . . . 138
Унбиш чыпчык, бер туңдырма . . . 140
Язгы әкият . . . 140
Язгы яңгыр . . . 141
Яңгыр . . . 142
Күке рөхсәт итте . . . 142

Чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Таң алдыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Яме артты күңелемнең . . . . . . . . . . . . . . 144
Кам-Кам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Кояшка үреләм! . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Болыт миңа булышты . . . . . . . . . . . . . . . 147
Күңелле! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Урманда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Юкә белән каен . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Эшкә оста, сүзгә кыска . . . . . . . . . . . . . . 150
Әбием килгән! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Татарча белмәүче кәҗәләр . . . . . . . . . . . . 152
Дәү әни . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Кемгә «кызым» диярсең? . . . . . . . . . . . . . 153
Тапкыр кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Әзер җавап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Кызып китте Алия . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Юату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Бака туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Алия «кәҗәләнә» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Бакчага барасы бар . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Ботка түгел... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Алтын сукмак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Дөрес аңлаган... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Телефон . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Карадым да карадым... . . . . . . . . . . . . . . 160
Айнур үпкәләде . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Бик ярата мине эш . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Үсәсем бар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Җиңелмени?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Кошлар туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Кызык икән... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Уйный-уйный үсәм мин . . . . . . . . . . . . . . 165
Килми калмас әле ул... . . . . . . . . . . . . . . 166
Мин андый малай түгел! . . . . . . . . . . . . . 167
Дәүдер җилнең авызы . . . . . . . . . . . . . . . 168
Акланды... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Литературно-художественное издание

*Зиятдинова Фирая Галиевна*

# ОГНЮ ХОЧЕТСЯ ЖИТЬ

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *В.В.Фомин.*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.07.2005.
Форматы 70×90 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 6,44. Шартлы буяу-оттиск 6,73. Нәшер-хисап табагы 6,15. Тиражы 2000 д. Заказ А-518.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.